# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

4/ 2022

*Күз явын алырлык итеп нечкәләп үрелгән челтәр әйберләр элек-электән зәвыклы саналган, югары бәяләнгән. Таякчыклар белән челтәр (кружева) үрү – борынгыдан килгән һөнәр. Петр I реформалары башлангач, челтәрдән үрелгән киемнәр модага кергән, Россиядә бу эш белән ныклап шөгыльләнүче үзәкләр барлыкка килгән.*









Фоторәсемнәр http://kukmor-rt.ru сайтыннан алынды

## Гасыр ярым дәвамында киез итек баскан җирлекнең үз фестивале бар. Ул – «Кукмара итекләре» – #ITEKFEST».





Башта бәйрәмне итек басу һөнәренә кызыксыну уяту, һөнәрчелек турында сөйләү, яшьләргә киез һәм тула серләрен өйрәтү өчен оештырсалар, елдан-ел анда катнашучылар саны арта бара, фестивальдә катнашу өчен Россиянең төрле почмакларыннан гаризалар җибәрәләр. Бирегә төрле кәсепләрне күрсәтәләр.

Яшен-картын үзенә җыйган фестиваль көнозын дәвам итә. Кунаклар ярминкәдә акчаларын кызганмый, чөнки мондагы кебек киез һәм тула итек, угги, ботинка, үкчәле итек, пима, калош һәм тагын әллә ничә төр продукцияне башка беркайда да очрату мөмкин түгел!



# ЭЧТӘЛЕК


**ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ**



4 **«Халык һөнәрчелеге – милли мәдәниятнең аерылгысыз өлеше»**

7 **«Иделкаем&Кариев варислары»: җиңүчеләр билгеле**

10 **«TAT·ARS·ТАН» конкурсына нәтиҗәләр ясалды**

**ХАЛКЫМНЫҢ ОСТА КУЛЛАРЫ**



12 Л. Шкляева **Киез киемнәрнең нуры бар**

18 Р. Мәһдиева **Татар курае**


**ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ**



23 Н. Равилова **«Каз өмәсе» – матур йола**

26 Р. Галкина **Каз мамыгы яшь киленгә – түшәк, ястык-мендәргә...**

**БЕЗГӘ ЯЗАЛАР**



29 Г. Мөхәмәдҗанова **Әтнәләрдә – «ӘтнәТуй»**

30 Л. Хәкимова **Хуш киләсең, «Сөлгеле капка» фестивале!**

**ЯЗУЧЫ МӨНБӘРЕ**



32 Г. Гыйльманов **Татар авылының таяну ноктасы – халык җыены**

**ӘДӘБИ МИРАС**

35 М. Бакиров **Татар халык эпосының типологик тасвирламасы һәм аны өйрәнүнең бүгенге торышы**

**ЭКСПЕДИЦИЯ**



39 Л. Мөхәммәтҗанова **Мөслимлеләрдән – халкыбыз хәзинәсенә рухи мирас**

44 И. Закирова **Изге теләк теле белик**

**БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ**



48 Г. Гыйльманов **Яңа китап**

49 **Албастылар**

**БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...**



54 **«UENFEST». «Инвожо».«Сочи Парк»**

57 **Киез итек читегем** (Җыр)

**ӨЙ КҮРКЕ – АШ**



58 **Чәк-чәк**

**ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ**

62 **Шахворд**



Түгәрәк уен

№ 4 (46) / 2022


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Разил Вәлиев
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Рәмзия Гайфетдинова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәүрузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 02.12.2022
Чыгу көне: 14.12.2022
Заказ: 066231 Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Визард» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Җиңү проспекты, 78

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.

**Тышлыкта: Чиләр салфеткасы.**
«Яңарыш» студиясе эшләнмәсе.
Балык Бистәсе районы.



© «Түгәрәк уен», 2022

# «Халык һөнәрчелеге – милли мәдәниятнең аерылгысыз өлеше»





**Халык һөнәрчелеге буенча сәнгать-эксперт советының чираттагы утырышы Габдулла Тукайның Казандагы әдәби музеенда узды.**

Биредә аерым осталар һәм предприятиеләр үзләре җитештергән әйберләрне кыйммәтле сәнгать әсәре сыйфатында тәкъдим итте. Алар арасында Алексеевск нәфис туку фабрикасы, «Көмеш барс», «Балчык магиясе» оешмалары һәм күп кенә шәхси эшмәкәрләр бар иде. Утырыш барышында экспертлар аларның эшләнмәләрен Халык һөнәрчелеге оешмалары реестрына кертү мәсьәләсен дә карады.

«Халык һөнәрчелеге – милли мәдәниятнең аерылгысыз өлеше. Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Мәдәният министрлыгы тарафыннан халык һөнәрчелеген саклау һәм популярлаштыру буенча зур эш башкарыла. Шул исәптән, халык һөнәрчелеген үстерү концепциясе әзерләнә», – диде Татарстан












мәдәни ресурслар үзәге директоры Алсу Мифтахова.

Оештыручылар билгеләп узганча, быел республика осталары утыздан артык ярминкәдә, осталык дәресләрендә һәм түгәрәк өстәлләрдә катнашкан. Болар арасында Кырымда, Иркутскида, Грозныйда узган төрле фестивальләр, Ульяновскида узган Федераль Сабантуй, Мордовиядә узган Бөтенроссия авыл Сабан туе, Якутиядә уздырылган Татарстан көннәре һәм башкалар бар. Республика осталары Сабантуйларда, «Каравон» фестивалендә, шулай ук, «Уяв», «Гырон-быдтон», «Питрау», «Семык», «Валда Шинясь», «Иван Купала» кебек республикада яшәүче җирле халыкларның милли бәйрәмнәрендә дә актив катнашкан.

Һөнәрчелеккә бәйле тагын бер яңалык – 2022 елда «Ел һөнәрчесе» республика бәйгесе игълан ителде. Ул «Интерпретация», «Сувенир», «Реконструкция», «Яшь һөнәрче» номинацияләрендә үтә. Аның икенче этабына 49 кеше үткән.





# «Иделкәем&Кариев варислары»: җиңүчеләр билгеле

**Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрында «Иделкәем&Кариев варислары» балалар-үсмерләр театр коллективлары һәм студияләренең XIII төбәкара фестиваль-конкурсына нәтиҗә ясалды.**

Быел конкурсның «Гран-при» дәрәҗәсенә Бөгелмә шәһәре «Техника йортының» «НОН-СТОП» халык АРТ-студиясе ия булды. Театр студиясе Л. Кэрролл әкияте мотивлары буенча «Новогодние приключения Алисы» әкияте белән катнашты. Режиссеры – Диана Барсукова.

«Курчак театры» номинациясендә I дәрәҗә лауреат исеме Менделеевск районының Балалар сәнгать мәктәбендә эшләп килгән «Золотой ключик» балалар театр коллективына бирелде. Алар конкурска Ю. Яковлевның «Друг по имени Умка» әкияте буенча куелган спектакль белән катнашты. Режиссеры – Марина Климова.

Финалга чыгучыларны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының бүлек мөдире Айрат Фәйзрахманов һәм Кариев театры директоры Луиза Янсуар бүләкләде.

«Фестивальгә катнашучы балаларга һәм аларның ата-аналарына бик зур рәхмәт. Бәлки, кемдер профессиональ артист та булмас, әмма театраль осталык сезгә алдагы тормышыгызда ярдәм итәчәк. Алга таба сезне «Театраль Идел буе» федераль театр конкурсында да катнашырга чакырабыз», – диде Айрат Фәйзрахманов балаларны котлап.

«Без бу фестивальне алдагы елларда да үткәрербез дип өметләнәм. Кариев театры – сезнең үз театрыгыз. Без спектакльләр

















сайлаганда һәм яңа проектлар әзерләгәндә сезнең аудиториягә йөз тотабыз. Бу иҗади алмашу безнең өчен бик кирәк», – диде Луиза Янсуар.

Жюри әгъзалары күп санлы гаризалар арасыннан 13 катнашучыны финалга чыгарган иде. Финалга чыгучылар ике көн дәвамында Кариев театрында үз спектакльләрен күрсәтте.

- Конкурста драма һәм курчак театры номинацияләре каралган.
- Балалар театр коллективлары конкурсы 1990 елда «Алтын битлек» исеме астында уздырыла башлый. Соңрак, 2011 елда бәйгенең исеме «Иделкәем» дип үзгәртелә. Ә 2019 елдан әлеге фестиваль-конкурска «Иделкәем&Кариев варислары» исеме бирелә. Конкурс-фестиваль быел Россия халыкларының мәдәни мирасы елы кысаларында уза.
- Бүгенге көндә Татарстанның мәдәният йортлары һәм гомумбелем бирү мәктәпләрендә 300дән артык балалар театр һәм курчак театры студияләре, коллективлары эшли. Аларда 10 меңнән артык бала һәм үсмер шөгыльләнә.
- «Иделкәем&Кариев варислары» фестивале республика балалар театр коллективларының дәрәҗәсен арттыру, репертуарны һәм режиссерларның иҗади эзләнүләрен баету максатыннан үткәрелә. Фестиваль Россия халыклары мәдәни мирасы елының төп чаралары федераль планына кергән.

# «TAT·ARS·TAH» конкурсына нәтиҗәләр ясалды



**Казанның Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концертлар залында «TAT·ARS·TAH» конкурс хәрәкәтенә нәтиҗәләр ясалды. Конкурста биш юнәлеш буенча – музыка, хореография, театр, сынлы сәнгать һәм декоратив-гамәли сәнгать – Татарстанның 45 районындагы сәнгать мәктәпләрендә укучы 5 меңнән артык бала катнашты.**

Концерт программасын Татарстан Республикасының Яшьләр симфоник оркестры башлап җибәрде. Оркестр белән Төньяк Осетия-Алания һәм Чечен республикаларының халык артисты Нина Шестопалова дирижерлык итте. Татарстан Республикасының Дәүләт камера хоры да концерт программасының затлы бизәге иде. Хор конкурс җиңүчеләре белән «TAT·ARS·TAH» конкурс хәрәкәтенең гимнын башкарды.

Залда затлы концерт күрсәтелсә, тамашачы фойеда конкурста катнашучы яшь рәссамнар һәм һөнәрчеләрнең иҗаты белән таныша алды.

«Шулкадәр күп талантлы балаларны җәлеп иткән конкурста жюрида катнашу – гаять катлаулы эш икән», – диде соңыннан конкурсның жюри рәисе, Татарстанның халык артисты, доцент, «Казан нуры» оркестры дирижеры Рәсим Ильясов.





Һәр баланың иҗатын карап, жюри 120 катнашучыны лауреат дип игълан итте. Шуларның 27се – I дәрәҗәдәге лауреат.

Җиңүчеләргә дипломны Татарстан Республикасының мәдәният министры урынбасары Юлия Әдһәмова, Татарстан Республикасының Дәүләт Советы депутаты Людмила Рыбакова һәм башка күренекле шәхесләр тапшырды.

I дәрәҗәдәге диплом ияләренә 30 мең сумлык сертификатлар да бирелде.









Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

**УЧАСТНИК КОНКУРСА ПРЕЗИДЕНТСКОГО ФОНДА КУЛЬТУРНЫХ ИНИЦИАТИВ**

# Киез *киемнәрнең* нуры бар

*Людмила ШКЛЯЕВА,*
*сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре*



**Дмитрий Маркин һәм Альбина Нуретдинова Казан шәһәренең Иске Татар бистәсендә**



**Людмила Шкляева ярдәмчеләре – Олег Козлов, Дарья Князева, Дарья Дергунова белән**

Традицион һөнәрчелеккә ярдәм өлкәсендә дәүләтнең мәдәни сәясәте Россия халыклары үзенчәлеген саклауның бер күрсәткече булып тора. Республикалар һәм өлкәләрдәге байтак грантлар һәм программалар да шушы максатка юнәлтелгән. Татарстанда һөнәрчеләр эшчәнлеген һәм кулланма гамәли сәнгать оешмаларын Мәдәният министрлыгы карамагындагы Мәдәни ресурслар үзәге барлап тора. 2020 елда барлыкка килгән «Киез НУР» иҗат берләшмәсе – шундый оешмаларның берсе. Бу берләшмә киез, тула басу белән бәйле традицияләрне кайтару юнәлешендә максатчан эшли, гореф-гадәтләребезне кулланма гамәли сәнгатьтә калку чагылдыра.



Хәзерге вакытта киез, тула басу кәсеп буларак сүнеп бара, әмма ата-баба һөнәрен дәвам итүче итекчеләр һәм киез белән эш итүчеләр бөтенләй юк түгел. Үзләрен киез басу эшендә сынап караган һәвәскәрләр дә, профессиональ рәссамнар да, хәтта дизайнерлар һәм модельерлар да бар. Алар хәзер итек кенә түгел, жилет, бүрек һәм башка әйберләр дә ясыйлар.

XXI гасырның беренче чирегендә күп илләрдә халыкара форумнарга багышланган киез костюмнар коллекцияләре күрсәтелә. Бу тема «Киез НУР» берләшмәсенә дә кызыклы булып, алар 2022 елның апрелендә Президентның мәдәни инициативалар фонды грантын отты. Грант татар стиле элементлары белән киездән һәм ефәктән заманча костюмнар әзерләү өчен дип тәгаенләнгән иде.

Беренче этапта рәссам М. Радионова эскизлар сериясе әзерләде. Алар – традицион татар киеменә таянып ясалган заманча костюм образлары. Рәссамның да, проект җитәкчесе буларак минем дә фикеребез бер – характерлы этник чалымнар күрсәтелгән яки киемнең традицион конструктив формаларын, төс һәм бизәк чишелешләрен берләштергән милли элементлар стилизацияләнгән заманча костюмны аеруча баета.



**Л. Шкляева һәм М. Радионова костюм эскизлары буенча фикер алышалар**





**Президентның мәдәни инициативалар фонды гранты буенча эшләнгән киез аяк киемнәре. 2022 ел**





**«Киез НУР» берләшмәсе иҗат иткән костюмнар**



**«Нәсел агачы»**





Студент-ярдәмчеләр «Киез НУР» остаханәсендә




Рабига Мәһдиева «Киез НУР» берләшмәсе иҗат иткән костюмнан. Г. Тукай әдәби музеенда. Казан, 2022 ел

«Киез НУР»ның бу проекты осталары һәм аларның ярдәмчеләре (В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты студентлары О. Бердникова, Д. Дергунова, Л. Иванова, Д. Князева, О. Козлов, Т. Табакова, А. Нуретдинова һәм Д. Маркин) татар стиле элементларының тәкъдим ителгән интерпретация вариантларын өйрәнеп, аларны юеш киез басу технологиясендә ясадылар. Эшләнмәләрнең декоратив өлешендә басу, чигү, сыру, корыдан басу ысулы белән төшерелгән бизәкләр һәм кошлар образлары кулланылган. Болар аяк киеме һәм баш киеме дә булган һәр кием комплектына үзенчәлек өсти. Эшләнмәләрдә татар халкы эстетикасына туры килгән яшел, зәңгәр, аксыл көрән, саргылт кызыл һәм коңгырт төсләр кулланылган. Дүрт хатын-кыз һәм бер ир-ат костюмыннан торган «Гаилә» коллекциясе шулай барлыкка килгән. Коллекция киез басу һөнәрен популярлаштыручы бәйгеләрдә, күргәзмәләрдә катнашачак. Болар барысы да Татарстанда әлеге традицион һөнәргә кызыксыну уятыр, заманча киемдә этностильне куллану активлашыр дигән өмет тудыра.



## *Бергәләп бизибез!*






# Татар курае

*Рабига МӘҺДИЕВА,*
*Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең матди булмаган мәдәни мирас бүлеге методисты*

**Җыр-моң – кешенең гомерлек юлдашы. Халык күңеленең иң нечкә хисләре җыр-көй белән бәйләнгән. Халык көйләре аһәңен күңел түренә үткәргән музыка уен кораллары гасырлар буе буыннан буынга күчеп, сакланып килә. Элегрәк кулдан ясалган сыбызгылар, мандолина, скрипка, гармун төп уен кораллары булса, заман үтү белән, алар камилләшә барган, тынлы уен кораллары, оркестр барлыкка килгән.**

Халык уен кораллары арасында курай – иң борынгысы һәм киң таралганы. Әлеге тынлы музыка коралы дөньякүләм уен коралларының иң танылганы. Татар курае флейта тибындагы башка уен коралларыннан төзелеше белән аерылып тора. Курай татар халкының барлык этник төркемнәрендә дә очрый һәм элек-электән үк киң таралган.

Курай турында беренче мәгълүматлар IV-XV йөзләргә караган Болгар кабер ташларында уелып калган, шулай ук, халык авыз иҗатында – әкиятләрдә, риваятьләрдә, җыр сүзләрендә, табышмакларда, әйтемнәрдә дә еш искә алына. Курайның төрле чыганакларда искә алынуы аның борынгы булуы турында искәртә. Гарәп сәяхәтчесе һәм географ Ибн-Рустәнең XX гасыр башына караган «Кыйммәтле хәзинәләр китабы»нда[1] курайны ике терсәк озынлыгында дип әйтелә[2].

Курайның иң борынгы төрләре урманда үскән курадан ясалган, алар «көпшә курай» һәм «нугай курае» дип аталган. Көпшә яки нугай кураеның уйный торган тишемнәре бары икәү. Нугай кураенда уйнарга өйрәнү өчен сәләт, зур тырышлык һәм түземлек кирәк. Сәяхәтче, академик П.С. Паллас XV гасырга караган «Россия империясенең төрле провинцияләре буйлап» исемле язмасында «Татарлар дудукны «кура» дип атаганнар. Бу дудукта уйнар өчен зур осталык кирәк, әгәр дә анда оста уйнаучы уйнаса, шул чагында көпшә авазы кече флейта авазына охшый», – дип искә ала[3]. Аваз чыгару принцибы буенча көпшә курай тавышы күп кенә төрки халыкларның тынлы уен коралы яңгырашына охшаш.

Адлер Тимергалинның «Миллият сүзлеге»ндә курай түбәндәгечә тасвирлана. «Курай – татар-башкорт тынлы музыка коралы, 600-700 мм озынлыктагы зонтиклы үсемлек сабагыннан (эче куыш курадан, камыштан, көпшәдән) ясалган флейта. Аның ян-якларында 4 һәм аскы өлешендә 1 уен тишеме була; курайчы шул тишемнәргә баскалап, 2-2,5 октава диапазонында моңлы авазлар чыгара. Курайның төрләре: агач курай, җиз курай, камыш курай (нәй), көпшә курай»[4]. Курай исеменең этимологиясе ахыргача ачыкланмаган, ләкин инструментның борынгы материалы-чатыр чәчәкле үсемлекнең төрки телләрдәге атамасы – «кура көпшә», «куыш сабак», «коры» сүзләре белән бәйле дигән фараз бар. Галим, музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов «Татар халык уен кораллары» исемле фәнни хезмәтендә билгеләп үткәнчә, XVIII гасырга кадәр чыганакларда «курай» сүзе искә алынмый: андый типтагы уен кораллары «флейталар» яки «сыбызгылар» дип аталган. IX-XI гасырларда курай «дудук» яки «сыбызгы» дип аталса, XII-XIV гасырларда бу уен коралы «флейта-Пана» дип исемләнгән, XV-XVI гасырларда – «свирель», ә инде XVIII гасырдан башлап көнкүреш тормышта «курай» термины ныклап кереп урнашкан»[5].


[1] Хвольсон Д.А. Ибн Рөстәнең «Кыйммәтле хәзинәләр китабы» әсәрләрен русча тәрҗемә һәм фәнни аңлатма белән бастырып чыгара: «Хазар Буртасалары, Болгарлар, Мадьярлар, Славяннар һәм Руслар турында хәбәрләр» (Санкт-Петербург, 1869).

[2] Хвольсон Д.А. Хазар Буртасалары, Болгарлар, Мадьярлар, Славяннар һәм Руслар турында хәбәрләр. – СПб., 1869. – 31 б.

[3] Паллас П.С. Россия империясенең төрле провинцияләре буйлап. 1-нче кисәк. – СПб., 1773. – 267 б.

[4] Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек / Төзүче авторы: Адлер Тимергалин. – Казан: Мәгариф, 2007. – 575 б.

[5] Нигмедзянов М.Н. Татар халык уен кораллары // Музыкальная фольклористика. 2-нче кисәк. – М., 1978. – Б. 266-297.



**Курайлар җыелмасы.**
**Р. Нуруллин фоторәсеме**



**«Тургайлар» курайларында уйнаучы балалар.**
**Р. Гайзетдинов фоторәсеме**

Үзенең фәнни эшендә галим шундый нәтиҗәгә килә: «...Безнең көнгәчә сакланып килгән курай – иң борынгы уен коралы. Гасырлар дәверендә ике тишемле нугай激 кураеның конструкциясе үзгәрә, камилләшә һәм уен тишемнәрен арттыру нәтиҗәсендә яңа төр курайлар барлыкка килә. Ике тишемле нугай курае Идел буеның башка халыкларында һәм башкортларда очрамый, димәк әлеге инструментны татар милли уен коралының иң борынгыларының берсе дип әйтергә була»[6].

Нугай кураенда теләсә нинди татар көен уйнарга мөмкин. Анда диатоник аваз рәтләренең барлык тавышларын чыгарырга була, диапазоны өч октавага кадәр җитә. Милизмнарны киң кулланып, курайның матур яңгырашына ирешеп, татар халык көйләрен башкарырга һәм хәзерге заман көйләрен дә уйнарга мөмкин.

Элеккеге заманда курай ясау өчен төп материал – кисеп киптерелгән чатыр чәчәкле үсемлек – «Урал реброплоднигы» булган. Хәзерге вакытта агач курай киң таралган, шулай ук алюминий яки башка төр металлдан да ясыйлар.

Мөгаллим, курайчы, курай ясау остасы Рафаэль Гайнетдин улы Гайзетдинов Татарстанда курайларны, югары технологик программа белән идарә ителүче станоклар кулланып, күпләп җитештерү мөмкинлегенә ирешкән бердәнбер оста. Бүгенге көндә Р. Гайзетдинов курайларны 14 төрле модификацияләрдә җитештерә.

1. Соль мажор пикколо
2. Фа мажор пикколо
3. Ми мажор
4. Ми бемоль мажор
5. Ре мажор
6. Ре бемоль мажор
7. До мажор
8. Кече октавалы Си мажор
9. Кече октавалы Си бемоль мажор
10. Кече октавалы Ля мажор
11. Кече октавалы Ля бемоль мажор
12. Кече октавалы Ре мажор
13. Нугай курае
14. Кушкурай.

[6] Нигмедзянов М.Н. Татар халык уен кораллары // Музыкальная фольклористика. 2-нче кисәк. – М., 1978. – 275 б.



**Рафаэль Гайзетдинов**





**Ре мажор курайлары**



**Фа һәм Ми мажор курайлары**

«Әгәр курай яхшы булсын дисәң, аны камилләштерүдән туктамаска кирәк, ә инде курай профессионал инструмент булсын дисәң, аның белән көн саен эшләргә кирәк», – ди Рафаэль Гайзетдинов. Аның девизы: «Курайның әһәмиятлелеге иң беренче чиратта курайчының көйләрне оста башкаруында, ә икенче урында курайның камил итеп ясалуында. Курайның сыйфаты начар булса, виртуоз курайчы да әллә ни уйный алмый».

Бүген Рафаэль Гайзетдиновның күңелен мена ниләр борчый – яшьләрне бу уен коралына тарту, уен осталыгын арттыру, курай ясау серләрен яшь буынга җиткерү. Шул максаттан, бик озак уйланып йөргәч, Рафаэль Гайзетдинов балаларны курай уйнарга өйрәтүнең уникаль методикасын әзерли. Методиканың төп асылы бик гади:



**Курайлар җыелмасы**




«Тургайлар» курайлар комплекты

**«Әгәр курай яхшы булсын дисәң, аны камилләштерүдән туктамаска кирәк, ә инде курай профессионал инструмент булсын дисәң, аның белән көн саен эшләргә кирәк», – ди Рафаэль Гайзетдинов.**

һәрбер нотага аерым курай ясала (До, Ре, Ми, Фа, Соль, Ля, Си, До) һәм шул сигез курайда сигез бала, дирижер ярдәмендә, чиратлашып, бер-бер артлы үз нотасын уйнап, көй чыгара. Көйне күмәк башкару балаларны берләштерә, чөнки бердәм булмасаң, көй өзелә. «Тургайлар» түгәрәгендә уйнаган бала тиз арада үзлегеннән курайда уйнарга өйрәнә ала.

Шулай итеп, Рафаэль Гайзетдинов сигез курайдан торган «Тургайлар» комплекты ясый башлый. Әлеге курайлар яңгырашы, озынлыгы, хәтта салават күперендәге кебек, төсе белән дә аерылып тора. Оста әлеге курайлар өчен бик күркәм футлярлар да эшләп куйган. Үзенең заманча җиһазлаштырган зур остаханәсендә Р. Гайзетдиновка ике оныгы да курай ясарга ярдәм итә. Рафаэль абый оныкларында музыкага мәхәббәт, югары зәвык һәм дәү әтиләренең эшен дәвам итүдә зур җаваплылык хисе тәрбияли.

Рафаэль Гайзетдинов бу эштә ялгыз түгел, республикабызның Мөслим һәм Ютазы районнарында да курай ясаучы осталар уңышлы эшли. Рафаэль Гайзетдинов кебек милли җанлы осталар, курайда уйнау нечкәлекләрен яшь буынга тапшыручы шәхесләр булганда, гасырлардан килгән уен коралы яңгырашы күңелләрне киләчәктә дә иркәләр.

Автор фоторәсемнәре



# «КАЗ ӨМӘСЕ» – *матур йола*

*Надирә РАВИЛОВА,*
*Кама Тамагы, Көрәле авылы мәдәният йорты мөдире*



**Каз – борынгы йорт кошларының берсе. Күңелле итеп каңгылдашкан ак мамыклы казлар һәр татар гаиләсендә бар. Ата-бабаларыбыз аларны асрауның да, куллануның да җаен белгән. Хәер, аны үстерү кешегә зур кыенлык тудырмый: казлар үзләре су буена төшә, үзләре кайта, кайткач биргәнне ашый. Ә елгалар туңгач, татар авылларында каз өмәләре башлана.**

«Каз өмәсе» – авыл кешеләренең казларны өмәләп, ягъни, бергәләшеп эшкәртүе. Традиция буенча, өмәдә күршеләр һәм туган-тумача ярыша-ярыша каз йолкый, каз итен эшкәртеп, әзерләп куялар, кызларга бирнә өчен мамыгыннан мендәр тутыралар. Өмә көнне эш беткәч, җырлашып кич утыралар.

Каз өмәсе башланыр алдыннан авыл мулласы яки аксакалы дога укый. Аннары ир-атлар каз суя, хатын-кызлар аны сөйләшә-көлешә йолкый. Кызлар, каз түшкәләрен бәкедә юарга дип көянтәгә асып, су буена төшә. Бирегә кызларны егетләр көтә. Уен-көлке белән казларны югач, егетләр гармун тартып җырлый-җырлый кызларны озатып куя.

Йорт хуҗабикәсе өмәдә катнашкан кунакларны чәй куеп көтеп тора. Табында – итле бәлеш, каз мае белән майланган коймаклар...

Ә кич белән инде зур табын корыла – кунаклар җыела. Башта табынга каз шулпасында пешкән токмачлы аш бирелә, аннары – каз үпкә-бавырыннан бәлеш, азактан – каз ите.

«Каз өмәсе»нең мәгънәләре күп төрле. Беренчедән, каз татарның ашатучысы. Икенчедән, «Каз өмәсе» – кешеләрне бергә җыючы матур йола. Өченчедән, бу йола үзара ярдәмләшүгә корылган. Аны кыз-балалар өчен, йорт эшенә өйрәнү дәресләре, дип тә атарга мөмкин.

Хәзер бу йола да онытыла башлады – чөнки яшәү рәвеше үзгәрде. Ни кызганыч, традицияләрне саклаучы өлкән буын китә бара, яшь буын шәһәргә күченә – дәвамчанлык бозыла.





Узган елның декабрендә Апас районының Урта Балтай авылында узган «Каз өмәсе» бәйрәменнән күренешләр. Биредә районның фольклор коллективлары каз түшкәләрен чишмәдә юу йоласын күрсәттеләр. Ул байлык теләп, чишмәгә төшә торган сукмакка каз канаты сибү, шулай ук милли, фольклор уеннар, җырлар белән үрелеп барды.















Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# КАЗ МАМЫГЫ
## *яшь киленгә – түшәк, ястык-мендәргә...*

**(«Мендәр тутыру» йоласы Мамадыш районының Югары Сөн авылында язып алынган)**

*Роза ГАЛКИНА,*
*Мамадыш районы мәдәният йортының халык иҗаты буенча методисты*

**Мендәр тутыру татар авылларында, милли традицияләр белән яшәгән татар гаиләләрендә борын-борыннан үткәрелеп килгән йолаларның берсе. Аның асылында кәләшкә бирнә өчен каз мамыгы тутырылган мендәрләр әзерләү ята. Йола гадәттә көзге кыр-бакча эшләре беткәч уздырыла.**



Әлеге йола гомер гомергә уен-көлке, мәзәк сүз, җыр-бию, белән үрелеп барган, һәр катнашучы йорт хуҗаларына җылы теләкләрен җиткергән. Йола вакытында йортка бөтен ерак туганнар, күрше-күләнгә кадәр чакырылган. Хәзер йола үтәлсә дә, гаилә эчендә генә уза.
Туй алдыннан кәләшнең якын туганнары – әнисе, түтиләре, апалары һәм ахирәт дуслары җыелып, мендәр тутыра. Шул кичне милли ризыклар пешерелә. Кияү белән кәләшкә, мул яшәсеннәр дигән теләк белән, парлы чәк-чәкләр әзерләнә. Пешерелгән парлы каз гаилә бәхете символы булып санала.



Ә инде мендәр тутыруга килгәндә, хатын-кызлар эшләрне бүлешкән: кемдер каз каурые сыдырган, кемдер сыдырылган мамыкны мендәр сүрүенә тутырган, ә кемдер чәй эчү өчен табын әзерләгән. Әлбәттә, әлеге кичтә җырлар да яңгыраган:

*Каз мамыгы яшь киленгә –*
*Түшәк, ястык мендәргә...*
*Гомерлек яр булса иде*
*Җаны әзелеп сөйгәнгә.*

*Төлке төшкән тарлауга,*
*Тимәс микән казларга?*
*Ахирәттә – алтын тәхет,*
*Егет сөйгән кызларга.*

Кемнең каурыйны ничек тотуына карап, элек кияүнең нинди булачагын фаразлаганнар. Мәсәлән, каурыйны кырыйдан алган кешенең кияве саран була дигәннәр. Әлбәттә, мондый юраулар шаяруга кайтып калган, җитди кабул ителмәгән.

Йола хуҗабикәнең тутырылган мендәрләрне күрсәтүе белән тәмамланган. Ул аларның матурлыгын, йомшаклыгын мактаган. Әлеге күперен торган зур мендәрләрне ясаучыларны мактаган. Аннары күз тимәсен өчен барлык катнашучылар җыелып мөнәҗәт әйткән:

*Яшь киленнең толымында*
*Чыңлый чулпы төймәсе.*
*Татарның күркәм йоласы –*
*Мендәр тутыру әмәсе.*

*Яшь киленгә – пар мендәрләр,*
*Тап кунмасын гомергә.*
*Йомшак булсын, гел пакъ булсын,*
*Сафлык бирсен күңелгә.*



Азактан кәләшкә кучтәнәчләр һәм бүләкләр биргәннәр (парлы каз, чәк-чәк, мамык шәл һәм башкалар).

*Яшь парларга пар каз бирү*
*Борынгыдан килгән гадәт.*
*Телик матур тигез тормыш,*
*Мәхәббәт, сөю-сәгадәт.*

*Яшь киленгә пар чәк-чәкне*
*Үзем бирәм бүләккә:*
*Балдан татлы телле булсын,*
*Бәләм булсын йөрәккә.*

*Аклык, сафлык билгеләре,*
*Әзен салсын күңленә –*
*Күз нурымны кушып үргән*
*Шәл саламын иңенә.*

Йола чәй табыны янында тәгәлләнгән.

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан



# Әтнәләрдә – «ӘтнәТуй»

Әтнә районында ел-яңа фольклор-этник фестиваль барлыкка килде: оештыручылар аны «ӘтнәТуй» дип атады һәм киләчәктә фестивальне республика күләмендә таныту максатын куйды.

«ӘтнәТуй» фольклор-этник фестивале Россия халыкларының мәдәни мирасын саклау елы уңаеннан август аенда Олы Әтнәдә узды.

«Туй – милли җыр-биюләребезне, уеннарыбызны саклап килгән бәйрәм. Нигә Әтнәбезнең үз туе булмаска тиеш?!» – диде Әтнә районы мәдәният бүлеге җитәкчесе Алия Хәнәфиева. Чыннан да, килешми мөмкин түгел. «Туй» сүзенә шатлыгы да, сөенече дә, хисләр янарышы да, күңелләр балкышы да, шул ук вакытта буыннан буынга дәвам иткән гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны саклап, киләчәк буынга тапшыру да кергән.

Фестивальнең төп максатын оештыручылар нәкъ менә бу якларда сакланып калган милли уеннарны, халык авыз иҗатын, онытыла барган җыр-биюләрне барлау, торгызу һәм халкыбызга кайтару дип билгеләгән дә инде.

Әтнә районы Башкарма комитеты җитәкчесе Айрат Каюмов үз чыгышында: «Яшь буынга милли тәрбияне фестивальләр, бәйрәмнәр аша тапшырырга тиеш булабыз. Алга таба фестивальне традицион бәйрәмгә әйләндерергә планлаштырабыз», – диде.

Ул көнне «ӘтнәТуй» фольклор-этник фестивале олысын да, кечесен дә бергә җыйды. Бәйрәмдә Әтнә районының үзешчән коллективлары чыгыш ясады. Туй булгач, кунаклар да була – Мари Иле республикасыннан, Арча һәм Казан шәһәрләреннән кунаклар – фольклор коллективлары, танылган җырчылар килгән иде.

Гасырлар буе халкыбызның рухи бердәмлеген ныгыткан, иң авыр чакларда да күңелен күтәргән, шатландырган һәм юаткан гармун моңына кушылып, Олы Әтнә авылы урамыннан җырлап бару да үзе бер тамаша булды. Чыннан да, гармун моңы беркемне дә битараф калдырмый. Гади эшчеме син, табибмы, академикмы – әлеге моң сине үзенә буйсындыра, сихри дөньяга алып керә китә. «РамДан» дуэты егетләренең дә: «Халкыбызның миллилеген тальян гармун аша җиткерергә тырышабыз», – диюе гади генә сүзләр түгел.

Фестиваль программасында башкалар биегәнне карау гына түгел, тамашачының үзенә дә бию өйрәнү мөмкинлеге тудырылган иде. Әтнә балалар сәнгать мәктәбе укытучысы – хореограф Марат Бариев Әтнә халкының бренды булган, буыннан-буынга тапшырылып килгән «Чабата биюе» буенча осталык дәресләре үткәрде.

Матур, күркәм узды фестиваль. «ӘтнәТуй» республика дәрәҗәсенә күтәрелеп, халкыбызның рухын, җанын дәвиласын иде. Замана казанышлары каршында милли йолаларыбыз, гореф-гадәтләребез югалмасын, яшьләрне битараф калдырмаслык фестивальләр ешрак булсын.

**Гөлнар МӨХӘМӘДҖАНОВА,**
**«Әтнә таңы» газетасы баш мөхәррире**





# Хуш киләсең, «Сөлгеле капка» фестивале!

Ташкичү авылы мәдәният йорты җитәкчесе Гөлфия Мәгъсүмова белән мәдәният йорты каршында эшләп килүче «Өммегөлсем» халык фольклор ансамбле коллективы (җитәкчесе Тәнзилә Вәлиева) фестиваль үткәрү теләген белдергәч, без аны гореф-гадәтләр, йолалар белән бәйләргә уйладык. Россия халыкларының мәдәни мирасын саклау елы уңаеннан оештырылган матур чара булачак ул. Ниятебезне Арча районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе җитәкчесе Илфар Әюпов белән Арча районы мәдәният йорты җитәкчесе Айрат Нурьязанов та күтәреп алды. Шулай итеп, районыбызда «Сөлгеле капка» фольклор фестивале туды!

Халкыбызның көнкүрешендә, көндәлек тормышында, йолаларында урын алган, җырларга кергән сөлге – фестивальнең символы иде. Исемен дә шуңа «Сөлгеле капка» дип атадык. Фестиваль «Халык җыры», «Халык биюе», «Инструменталь башкару», «Фольклор этнографик күренеш» номинацияләрен үз эченә алды.

Фестивальдә үзебезнең районндагы иҗат коллективлары гына катнашыр дип уйласак, социаль челтәрләргә мәгълүмат куйгач, ул киң колач җәйде. Катнашырга теләк белдерүчеләрдән 40тан артык гариза килде. Алар арасында Әтнә, Мамадыш, Биектау, Яшел Үзән районнарыннан һәм Мари Эл Республикасыннан, Казан шәһәреннән килгән иҗат коллективлары да бар иде.

«Өммегөлсем» халык фольклор ансамбле фестивальгә килүчеләрне Ташкичү мәдәният йортында җыр-моң, биюләр белән каршы алды. Аннары бергәләп, авыл мәктәбендә урнашкан бөек шәхес, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗани музеена сәяхәт кылдык. Шулай ук кунакларны данлыклы Ташкичү мәчете тарихы, эшчәнлеге белән таныштырдык. Фестиваль узачак матур табигатьле мәйданга барлык катнашучылар җырлашып, җәяү төште.

Тантаналы чара ачылышында Арча муниципаль районы







Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Эльвира Вафина катнашты. Район җитәкчелеге тарафыннан «Сөлгеле капка» фольклор фестивалено зур игътибар бирелүе безнең өчен бик мөһим. Үзенең чыгышында Эльвира Шамилевна фестивальнең дәвамлы булуын теләде.

Мәйданда катнашучылар казанда пешкән тәмле пылау белән дә сыйланды, көн дәвамында уен мәйданчыклары һәм сәүдә нокталары эшләп торды. Биредә матди ярдәм күрсәтүче иганәчеләрне, авыл халкын һәм Ташкичү авылы җирлеге башлыгы Фәим Фәйзуллинның хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк.

«Беренче коймак төерле була» диләрме әле?! Әмма мин төерләрен күрмәдем. Шулай да фольклор фестиваль булгач, күмәк коллективларны күбрәк күрәсем килде. Фестивальнең, иң беренче чиратта, тәҗрибә туплау мәйданы булуын да аңладым. «Бездә дә шундый чара оештырырга һәм шулай эшләргә кирәк», – дип килеп әйтүчеләр дә булды. Башкалар бездән үрнәк ала икән, димәк, фестиваль аша үзебезне күрсәтә алганбыз. Фестивальдә яшьләрнең катнашуы сөендерде. Аларның күбесе «Инструменталь башкару», «Халык биюе» номинацияләрендә чыгыш ясады, фольклор күренешләрдә катнашты.

Мари Элдан килгән «Тулган ай», «Шийгорно», «Олык марий» фольклор коллективлары, «Сардаял сем», «Таң йолдызы» вокаль ансамбльләренең чыгышлары аеруча күңелдә калды. Алар милли киемнәрдән үз халыкларына хас йолаларны күрсәттеләр.

Без – оештыручылар әлеге фестивальнең алдагы елларда да булуын, киләчәктә тагын да камилләшүен телибез. Катнашучыларның барысы да диплом, истәлекле бүләкләр белән бүләкләнде.

**Ләйлә ХӘКИМОВА,**
**Арча районы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе**

Автор фоторәсемнәре

# *Татар авылының таяну ноктасы –* ХАЛЫК ҖЫЕНЫ



*Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,*
*язучы, әдәбият белгече*

**Бүгенге татар авылының хәле, яшәеше, язмышы каләм әһелләрен дә бик борчый, тирән уйларга сала, аларның да язмышына әверелә. Чынлыкта, татар әдәбиятының төп темасы да элек-электән авыл темасы булган, аның төп геройлары да – авыл кешеләре, йә булмаса, авылдан чыгып, халык һәм ватан язмышына дучар булган каһарманнар. Язучы-әдипләребезнең дә күпчелеге – авыл тудырган, авыл үстергән, тәрбияләгән милләт уллары, милләт кызлары! Милләтебезнең рухы, җаны кайда яши дисәгез, мин һич тә икеләнмичә: «Авылда яши», – дияр идем. Бу рух, бу җан үз язмышларын авыл белән бәйләгән татарларыбызның йөрәк тамырларына чәчелеп яши...**

Әлбәттә, татарның милли идеясе авыл белән бәйле. Авыл бар икән – тел бар, моң бар, рух бар, аның легендасы бар, хикмәтле сүзе – фәлсәфәсе бар, иң мөһиме, татарның әхлак кодексы бүген авылда сакланган. Шушы нигез ташларын җыеп торган ЙОЛАСЫ исән әле татарның!

Мин үзем бик күп уйландым, минем белән бергә әсәрләремдәге геройларым да уйланды: авылны авыл итә торган, димәк ки, аны саклап калуда рухи көч һәм илаһи чыганак була алган ТАЯНУ НОКТАСЫ кайда? Тарихи хәтердәме, диндәме, мәктәптәме, ыру-нәсел тәгълиматындамы, Сабантуй көрәш-бәйгеләрендәме, җырда яисә моңдамы, эшмәкәрлектәме? Бу сорауга җавапны мин үзем туып үскән якларда, Башкортстанның Дүртөйле районы авылларында таптым. Татарлар яшәгән бу төбәк нәкъ менә үзенең ХАЛЫК ҖЫЕННАРЫ белән әсир итте мине.

Ә бит катлаулы тарихыбызның иң авыр вакытларында татар авылын, димәк ки, милләтне, ХАЛЫК ҖЫЕНЫ саклап калган. Һәм аның мәгънәсе дә күпкә киң, тирән.

Тарихтан шул билгеле: татар авылларында җыеннар өч-дүрт көн барган. Яз ахырларында, җәй башларында, еш кына чәчүдән соң, якын-тирә авыллар, үзара килешеп, ОЛЫ ҖЫЕН оештырган. Алдан билгеләнеп куелган авылга, еш кына базар авылына, тирә-яктан берьюлы берничә йөз олау килеп тулган...

Балаларның «Карга боткасы»ннан башланып киткән ул, анысы инде яшь буынны үзара аралаштыру өчен кирәк булган. Аннары көрәшләре, ат чабышлары, капчык сугышлары һәм җыр-биюләре белән Сабантуй кергән. Җыенның бер көне үзара мөнәсәбәтләрне ачыклауга, килешүләр төзүгә, җир-ызан, су, буа, болын, урман бүлешүгә, аларны куллану юлларын эзләүгә багышланган. Юлларны, күперләрне карау, кибетләр ачу, зиратларны төзекләндерү, ятимнәргә, ялгыз картларга булышу, мәктәп-мәдрәсәләр торгызу, мәчет









Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

төзү, хакимияткә дәгъвалар язуга багышланган табыннар аеруча шау-шулы узган. Кыскасы, бер ел буе җыелып килгән проблемалар кумәкләп хәл ителгән. Бу чара белән авыл старосталары, муллалар һәм аксакаллар шурасы җитәкчелек иткән. Кабул ителгән килешүләрне хуплап, җомга вәгазьләре һәм догалар багышланган, азаннар әйтелгән. Соңгы көнне яшьләрнең «түгәрәк уеннары», йөзек салышлар, капма-каршы җырлы-биюле йолалар, чәчәннәр ярышы бизәгән. Дүрт көн буе базар гөрләп торган, сату-алу, мал алмашу барган, алыш-биреш буенча килешүләр төзелгән...

Менә шундый җыеннар турында иде бүгенге сүзем. Чынлыкта, халык кадерсезләнгән, дәүләтеннән мәхрүм ителгән бер мәлдә, ҖЫЕН ЙОЛАСЫ милләт тамырларын бәйләп, саклап калган.

Безгә бу тарихны барларга – йолаларны кайтарырга кирәк. Бәхетебезгә, җыен йолалары кайбер төбәкләрдә бүген дә яши, гамәлдә. Һәрхәлдә туган ягым Дүртөйле төбәгендә андый йолаларны хәзер дә очратырга мөмкин. Мәсәлән, элек-электән Әсәндә «Күәш җыены» уздырылып килде. Ул Агыйделгә коя торган Күәш елгасы буена урнашкан авылларны берләштерә. Шулай ук «Өчбүлә җыены»нда булганым бар, анысының үзәген игенчеләр һәм эшмәкәрләр тәшкил итә. Чынлап та, Өчбүлә төбәге авыллары гомер-гомергә авыл хуҗалыгы буенча иң алдынгы аграр хуҗалыклардан санала. Әсәндә исә күбрәк төзелеш, сәүдә, эре маллар культы. Шулай ук рухи юнәлеш, әдәбият-сәнгать, халык иҗаты һәм йола көчле. Чәчәнлек традициясе көчле булган, һөнәрчелеккә, бакчачылыкка элек-электән һәвәс авыл ул. Бүген, ягъни соңгы ун-унбиш елда, Әсәннең тирә-як яланнарында дистәләгән яңа урам пәйда булган икән, димәк, ҖЫЕН ЙОЛАСЫ үз эшен эшли, авылны саклый, аны ныгыта, үстерә һәм үрчетә...

«Нигә яңа йола уйлап чыгарырга, Сабантуй бар бит инде», – диярсез... Сабантуй нигездә кунаклар өчен бәйрәм ул. Сабантуйга татар кешесе туган авылына кунак булып, күңел ачар өчен кайта. Сабантуй, чынлап та, ЗУР ҖЫЕНның бер бизәге була ала. Әмма авыл мәнфәгатен Сабантуй кысаларында гына кайгыртып бетереп булмый. Безгә авылларда ЭШЛЕКЛЕ ҖЫЕННАР оештырырга кирәк. Кайчандыр бәхет эзләп чыгып киткән татар кешесе туган авылына ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘШҮ ӨЧЕН, авылның язмышын хәл итүдә катнашу өчен кайтсын! Кайтып, авылда торып калырга, язмышын кабат җир белән бәйләргә уйласа, тагын да әйбәт.

ҖЫЕН ЙОЛАСЫның үз фәлсәфәсе, кануннары, логикасы, эчтәлеге бар, әлбәттә. Мисалга һаман шул үзем белгән, күргән, язмышымда калган «Күәш җыеннарын» китерәсем килә. Туган авылым оештырган олау эчендә, тәртә башларына кызыл башлы сөлгеләр бәйләнгән, дугаларына кыңгыраулар тагылган тарантасларда мәйданга килеп керәсең, авыл тарихын, шәҗәрәсен игълан итәсең, авыл Советы, аграр хуҗалык башлыклары, имамнар, аксакаллар, чәчәннәр катнашында узган «түгәрәк өстәлләр»дә, хәзерге тел белән әйтсәк, диспутларда катнашасың... Кайдадыр янәшәдә генә игенчеләрнең үз мәйданы, эшмәкәрләрнең үз «өстәле», дин әһелләренең үз «келәмнәре»... Барысының да күңелләрендә – «авыл язмышы»...

Әйе, мин боларны үзем күрдем, бу йолаларда үзем катнаштым... Авыл белән, аның мәктәбе, балалар бакчасы, зираты, мәчете, фермалары, кибетләре, юллары белән бәйле проблемаларны хәл итүдә янып-көеп йөргән татарларыбыз белән аралаштым. Җыеннардан соң парланган яшьләрнең туйларында да утырырга туры килде... Җыен барышында, дәррәү кузгалып, кемнеңдер бурасын күтәрергә киткән милләттәшләрем дә күз алдында...

Үземнең нәсел агачын презентацияләүдә катнашу мизгелләрен дә мәңге онытасым юк. Әйе, җыенда һәр кеше үз авылын, үз нәселен тәкъдир итәргә тиеш. Бу – әлеге йоланың төп таләбе. Мин дә матур итеп эшләнгән шәҗәрәмне байрак итеп күтәреп чыктым. Янәшәмдә авылдан чыккан күркәм затлар, күренекле имамнар, авыл алдынгылары, исемнәре телгә кергән фермерлар, эшмәкәрләр бар иде. Алар да үз «байраклары» белән. Авыл осталары, алдан ук килеп, һәр авылның үз утарын, йортын яисә тирмәсен корган, эшмәкәрләр, сатучылар үз сәүдә рәтләрен булдырган. Минем моңа кадәр дә, моннан соң да бу кадәр югары кимәлдә оештырылган милли-патриотик чараны күргәнем булмады.

Нәкъ шул ҖЫЕН ЙОЛАСЫ вакытында татарның милли идеясе турында уйландым да инде. Аның төп мәгънәсе татар авылын саклап калуда гына түгел, аны яңартуда һәм үстерүдә булуына инандым. Бу идеяне тормышка ашыру өчен, бары тик теләк һәм яңа дәвер тудырган мөмкинлекләрдән файдалана белергә генә кирәк!



# ТАТАР ХАЛЫК ЭПОСЫНЫҢ ТИПОЛОГИК ТАСВИРЛАМАСЫ *һәм аны өйрәнүнең бүгенге торышы*



*Марсель БАКИРОВ,*
*фольклорчы галим, тюрколог,*
*Татарстанның атказанган фән эшлеклесе*

## ГЕРОИК ЭПОС: ТӨРЛӘРЕ ҺӘМ ЯШӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Фольклористикада «эпос» термины жанр атамасы буларак кулланыла, яисә узганнар турында әкияти-мифологик яки героик планда, йә булмаса мәхәббәт-романтика рухында бәян итүче фольклор әсәрен күздә тота. Грек телендә «сүз» һәм «хикәяләү» дигән мәгънәләргә туры килә һәм халыкара термин буларак йөри. Төрле халыкларда эпоска параллель рәвештә кулланыла торган үз терминнары да бар: Кавказ халыкларында – «нард», русларда – «былина», карел-финнарда – «руна», якутларда – «олонхо». Фарсы йогынтысын кичергән төрки халыкларда, шул исәптән татарларда исә «дастан» һәм «кыйсса» дигән атамалар кулланыла.

Фәндә эпик хикәятләр яки дастаннар, мифологик ышанулар һәм каһарманнар турындагы әкиятләр җирлегендә, борынгы ыруглык мөнәсәбәтләре җимерелүгә йөз тоткан чорларда ук барлыкка килә башлаган дип санала. Алга таба аларның үсеше феодализм дәверендә дәвам итә, җәмгыять кысаларында әлеге төр әсәрләргә яңадан яңа сыйфатлар өстәлә. Әмма җәмгыятьтә күпмедер дәрәҗәдә патриархаль мөнәсәбәтләр яки искелек калдыклары саклануы аркасында, һәм, янә килеп, традицион мирас буларак, архаик эпосның аерым үрнәкләре бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән.

Эпос белгечләренә яхшы билгеле: дастаннарның күпчелеге героик характерда, чөнки аларның төп һәм үзәк герое – баһадир-алып. Ул еш кына туганда ук батыр булып туа яки яу кырында батыр-баһадирга әверелә һәм аждаһалар, төрле явыз мифик көчләр белән кискен көрәш алып бара. Дошманнарын җиңәргә аңа үзе кебек батыр аты, куәтле җәясе яки кылычы булыша. Серле балдак, көзге, тарак, терек суы кебек магик предметлар ярдәмендә дошманың җиңгән тылсымлы әкият героеннан аермалы буларак, архаик эпос герое үзе зур физик көчкә ия һәм дошманын да ул үз көче белән җиңеп чыга. Үзәгендә нәкъ менә батыр-алып образы торганга күрә дә, мондый халык эпосларын «героик» яки «батырлар эпосы» дип атау кабул ителгән.

Фольклор фәнендә һәм тюркологиядә героик эпос-дастаннарны өч төргә бүлеп йөртәләр: 1) архаик яки, икенче төрле – әкияти-мифологик эпос; 2) классик эпос; 3) тарихи эпос. Бу өч тип яки өч дастан төре героик эпос үсешенең эволюцион баскычларын чагылдыра һәм бер-берсеннән чынбарлыкны гәүдәләндерү ысулы һәм тарихилык дәрәҗәсе ягыннан аерыла. Безнең өчен шунысы бик әһәмиятле: татар халык авыз иҗатында, шулай ук татар фольклорчыларының тикшеренүләрендә героик эпосның һәр өч төре дә конкрет әсәрләр мисалында күрсәтелгән. Телләр охшашлыгы һәм эпик көчеш-йогынтылар, мәдәни-идеологик

багланышлар аркасында, татарларның эпик иҗаты күпчелек очракта гомумтөрки эпик мираска барып тоташа. Әмма татар эпос-дастаннары, мөстәкыйль һәм үзенчәлекле версия буларак, һичшиксез, милли-этник характерда.

Эпос белгечләре фикеренчә, Себер регионы төрки халыкларында (саха, алтай, шор, тыва, хакас) эпосның архаик, екияти-мифологик төре яхшырак сакланган. Бу, әлбәттә, әлеге халыкларда җанлы башкару белән бәйле чичәннәр традициясенең озаграк саклануы, язма әдәбиятның исә соңрак барлыкка килүе белән бәйле. Нәкъ шул сәбәпле Урал башкортлары иҗатында да, Идел-Кама регионы татарларына караганда, дастаннар күбрәк сакланган. Янә килеп, Себер татарлары арасында да халык эпосы традицияләре, Казан татарлары белән чагыштырганда, киңрәк таралган, чөнки аларда язма әдәбият шактый соң барлыкка килгән.

Казан яки Идел буе татарларының эпос мирасына килгәндә, аларда героик-эпик дастаннар, башлыча, язмача иҗат ителгән. Бу Казан татарларының кульъязма форматтагы язма мәдәният варислары яки дәвамчылары булуына бәйле. Баштарак эпос-дастаннар язылып, «кульъязма китап» сыйфатында таратылса, XVIII гасырның беренче чирегеннән алар басма рәвештә яки аерым китап рәвешендә нәшер ителә башлаганнар.

Казан татарларның язма мәдәниятка омтылышы каяндыр ишеткән дастаннарны язмада теркәп кую белән генә чикләнмәгән, ә әлеге жанр үрнәкләрен язып, ягъни язма рәвештә иҗат итүгә китергән. Мондый әсәрләр импровизация юлы белән иҗат ителгәннәр, һәм ярым көйләп укыла торган сөйләмә дастаннардан аермалы буларак, кулдан язылган текстны укуга исәп ителгәннәр. Иң мөһиме – андый текстлар редакцияләнгән һәм күпмедер күләмдә эшкәртелгән, импровизацион сөйләмә дастаннар өчен хас поэтика һәм традицион эстетика-стиль нормаларының, язма әдәбият кысаларында формалашкан сәнгати-поэтик чаралар белән үрелүе югарылыгына күтәрелгән. Өстәвенә, Чичән-импровизаторның исеме еш кына билгесез кала, ә бирердә авторлык яки шәхси башлангыч үз урынын ала. Чөнки эпосның язма версиясен иҗат итүче үз исемен күрсәтеп калдырырга тырыша, кайчакта авторы билгесез текстны эшкәртүче талантлы кучереп язучы да, редактор-реставратор да автордашка әверелә.

## ЭПИК МИРАСНЫ ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫННАН

Татарларның язма мәдәнияте системасында эпик иҗатның булуын һәм аның аерым жанр тәшкил иткәнлеген белгечләр XIX гасырда ук таныса да, бу өлкәгә бәйләнешле җыю эшчәнлеге һәм махсус тикшеренүләр узган йөз урталарында гына башкарыла башлады. Әлеге эшчәнлеккә, фәнни юнәлешкә алынучы һәм нигез салучылардан педагог Н. Хәкимне, язучы Н. Исәнбәт һәм фольклорчы Х. Ярмине аерып күрсәтергә кирәк. Мин монда баштагы ике белгечне «Идегәй» дастанын сөйләмә һәм язма вариантларда халыкка ирештерүчеләр буларак күздә тотам. Х. Ярми исә беренчеләрдән булып, Себер татарларыннан «Кузы Көрпәч һәм Баянсылу» дастанын язып алган һәм фәнни аңлатма биргән.

Татарларның эпик мирасын өйрәнүнең хәзерге торышы турында сөйләгәндә, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының эшчәнлеген билгеләп үтү зарур. Бу институтның галимнәре Флора Әхмәтова белән Фатих Урманчеев үзләренә кадәр башланган фәнни юнәлешне эстафета кебек кабул итеп алдылар һәм эпос белгечләре булып җитештеләр. Флора Әхмәтова 1984 елда басылып чыккан 12 томлык Татар халык иҗатының «Дастаннар» томын төзүче һәм аңа гомумиләштерелгән кереш фәнни мәкалә язучы буларак аерым игътибарга лаек. Ә 2004 елда ул үз инициативасы белән татар дастаннарының тулыландырылган аерым җыентыгын тәкъдим итте.

Озак еллар институтның фольклор бүлеген җитәкләгән Фатих Урманчеев, татар халык эпосының бөтен типларын һәм төрләрен, аеруча героик эпосларны тирәнтен өйрәнеп, байтак фәнни хезмәтләр язды. Шундыйлардан аның «Героический эпос татарского народа», «Народный эпос Идегей» һәм «Тюркский героический эпос» дигән монографияләре фәнни җәмәгатьчелек һәм киң катлам укучылар тарафыннан яратып каршыланды.

Эпик мирасның алдагы язмышы әлеге остазларның дәвамчылары кулында. Әлеге мирасны өйрәнү белән хәзер фольклор бүлеге хезмәткәрләре Лилия Мөхәммәтҗанова һәм Илсөя Закирова шөгыльләнә. Л. Мөхәммәтҗанова «Татар китап дастаннары: жанр барлыкка килү тарихы һәм поэтика» дип аталган диссертация хезмәтендә – «Каһарман Катил», «Чура батыр», «Күр углы Солтан» героик дастаннарның язма версияләре, шулай ук «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Таһир-Зөһрә» исемле романтик һәм мәхәббәт дастаннары мисалында – әдәбият белән фольклор арасында торган үзенчәлекле иҗатның концепциясен бик уңышлы эшләп чыкты. Лилия Мөхәммәтҗанованың диссертациягә нигез булган әлеге хезмәте аерым китап булып басылды.

И. Закирова исә үзенең Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорларына мөнәсәбәтле халык иҗатына багышланган кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен «Алпамыш», «Түләк», «Ак Күбек», «Гайшә улы Әмәт» дастаннарының милли версияләрен, шулай ук, «Кузы Көрпәч һәм Баянсылу» романтик-мәхәббәт дастанын өйрәнүгә багышлады.

Болардан тыш, Институт тарафыннан планлаштырылган 25 томлык татар фольклоры тупланмасының эпоска багышланган томнарын да Илсөя Закирова белән Лилия Мөхәммәтҗанова әзерләде. Һәм сүз уңаенда өстәп әйтергә кирәк, әлеге томнарның фәнни мөхәррире мин булдым.

Азмы-күпме тулы картина тусын өчен, монда әлбәттә, Казан федераль университеты галимнәренең эпос темасына бәйләнешле эшчәнлеге турында да белешмә бирү соралып тора. Күп еллар буена тарих кафедрасын җитәкләгән Миркасыйм Госмановның «XVII-XVIII гасыр татар тарихы чыганаклары» дип аталган капиталь хезмәтендә, мәсәлән, гомуми планда булса да, тугыз дастанхикәят анализлана. Шуларның сигезе, «Идегәй»дән калганнары, Чыңгыз нәселеннән булган Алтын Урда ханнарына багышланган. Ни кызганыч, иң элгәрге «кульъязма китап» рәвешендәге китабы дастаннарның башлангыч үрнәкләрен беренче мәртәбә фәнни әйләнешкә керткән әлеге хезмәт тә, шулай ук дастаннар үзләре дә алга таба эпос белгечләре тарафыннан махсус рәвештә анализланмаган. Миркасыйм Госмановның «Каурый каләм эзеннән» (Казан, 1994) дип аталган китабында исә кайбер татар эпос-дастаннарының тарихи тамырлары һәм иҗат ителгән урыны турында кызыклы мәгълүматлар чагылыш тапкан.

Мин фәкыйрегезгә дә заманында, фольклорчы буларак, халкыбызның эпик мирасын өйрәнү белән шөгыльләнергә туры килде. Татар эпосының типологиясен һәм жанр-тематика төрләрен без тарихилык белән тыгыз рәвештә бәйләп өйрәндек, ягъни, аларда чынбарлык белән бәйле тарихилыкның ни дәрәҗәдә чагылыш табуы анализланды. Архаик яки екияти-мифологик дастаннар, классик дастаннар һәм тарихи дастаннар бер-берсеннән нәкъ шушы яссылыкта аерылалар һәм героик эпос эволюциясе-үсешенең өч баскычын тәшкил итәләр. Конкрет әсәрләр мисалында анализланган әлеге дастаннар татар фольклоры буенча вузлар өчен безнең тарафтан язылган дәреслектә һәм «Татар фольклоры» дип аталган рус телендә чыккан монографиядә урын алды.

КФУның Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институты доценты Миләүшә Хәбетдинова әле күптән түгел генә «Нәкый Исәнбәт» (Казан: Җыен, 2021) дип исемләнгән фәнни-популяр җыентык бастырып чыгарды. Китапның кыйммәте язучы һәм атаклы фольклорчының галимә тарафыннан өйрәнелгән һәм тупланган шәхси архив материалларыннан торуында. М. Хәбетдинова анда аз өйрәнелгән фактик материалларга таянып, Н. Исәнбәтнең Башкортстанда һәм Себердә «Идегәй» халык эпосын кат-кат язып алуы һәм әлеге героик дастанның китап вариантын иҗат итүе тарихын торгыза.

## ЧУРА БАТЫРНЫҢ РЕАЛЬ ПРОТОТИБЫ БУЛГАНМЫ?

Мәдәни ресурслар үзәгенең бүлек мөдире Рәмзия Гайфетдинованың Казан дәүләт мәдәният институтында яклаган диссертациясе дә югарыда саналган фәнни хезмәтләргә килеп ялгана. Үзенең әлеге эшендә ул эпос гыйлеме өлкәсендә татар дастаннарын беренче буларак мәдәни-фәлсәфи яссылыкта өйрәнеп, кызыклы нәтиҗәләргә килде.

Чыгышымның азагында кайбер бәхәсле мәсьәләләргә дә тукталасым килә. Сүз тарихи фактлар белән ярашмаган, кискен каршылыкка керә торган карашлар турында бара. Белүебезчә, «Чура батыр» дастанында төп герой татар дәүләтчелеге юкка чыккан чорда Казанны саклаучы каһарман сыйфатында тасвирлана. Фольклорчылардан Фатих Урманчеев һәм аның шәкерте Лилия Мөхәммәтҗанова үзләренең тикшеренүләрендә Казан бәге-морзасы Чура Нарыковны Чура батырның прототибы итеп карыйлар. Моны раслау өчен алар ата белән улның исемнәре Чура һәм Нарык (Нәрекъ) булуын һәм дә әлеге исемнәрнең Казан морзасының Чура Нарыков атлы булуы белән сүзмә-сүз тәңгәл килүен төп дәлил итеп китерәләр.

Әмма Ә. Диваев, А. Орлов, В. Жирмунский, Һ. Атласи хезмәтләренә таянып ясалган безнең тикшеренүләр башка нәтиҗәләргә китерде: бу эпос-дастанның «Кырык ногай батыры» эпик циклына керүе ачыкланды. Әлеге дастан «Шора батыр» исеме белән иң элек казахлар һәм

ногайлар аралашып яшәгән Көнбатыш Казахстанда – Кече җүз (урда) төбәгендә барлыкка килгән. Һәм дастанның бу баштагы версиясендә элгәрге заманда казахлар белән калмыклар арасында булган көрәш һәм бәрелешләргә бәйле тема чагылыш тапкан. Ә. Диваев белән А. Орловның тикшеренүләреннән, шулай ук «Шора батыр» һәм Нарык (Нәрекъ) исемле дастаннарның архаик версияләреннән аңлашылганча, Казан дип аталган һәм калмыклар белән көрәшер өчен Чура батыр килгән шәһәр асылда Идел буендагы тарихи Казан түгел, ә Алмалык төбәгендәге шул ук исем белән аталган башка элгәрге шәһәр, икән.

Казан татарларының беркайчан да калмыклар белән сугышмаганын, казахларның көнчыгыш яктан ойратлар (калмыклар) белән чиктәш булып, XV-XVI гасырларда шуларның һәлакәтле һөҗүмнәренә дучар ителүен искә алсак, «Чура батыр»ның татар версиясенең кайдан башлангыч алуы яхшы аңлашыла. Казахларның «Шора батыр»ында да, татар дастаны «Чура батыр»да да сюжетлар уртак, геройларның исемнәре дә уртак, хәтта шәһәрләр исеме дә бер үк. Җитмәсә сүз ике әсәрдә дә басып алучыларга каршы көрәш турында бара. Нәкъ менә шәһәр исемнәренең тәңгәл булуы һәм туган җирне дошманнардан саклау мотивының уртаклыгы аркасында Казах героик дастанының сюжеты ногайлар аша безнең Идел буена үтеп кергән дә инде, һәм, трансформацияләнеп, татар героик дастанының эпик версиясенә әверелгән. Әгәр, чыннан да, Чура исеме дә (казах вариантында Шура), Нәрекъ/Нарык та иң башта казах дастанында булган икән, димәк, антропонимнар тәңгәллегеннән тыш, әлеге исемнәрнең Казан морзасы Чура Нарыковка бер катнашы да юк булып чыга.

Икенчедән, исемнәрнең аваздашлыгы аркасында гына бу Казан морзасы ике эпос белгече тарафыннан дастан герое Чура батырның прототибына әверелдерелсә дә, чынлыкта Чура Нарыков бөтенләй дә Казанны саклаучы булмаган, киресенчә, Мәскәү кнәзьлегенең империячел мәнфәгатьләрен яклаган. Әлеге сатлык җан Иван Грозный хөкүмәте биргән бүләкләргә алданып, Сафагәрәй һәм Сөембикәгә, аларның Казан ханлыгының бәйсезлеген һәм бөтенлеген яклаган сәясәтенә каршы чыккан. Ачыклап әйткәндә, ике мәртәбә Мәскәүгә үз кешеләрен җибәреп, русларны Казанга яу белән килергә чакырган, ханлыкның бәйсезлеген яклаган кешеләрне, шул исәптән, Сафагәрәйне дә, әсир алып, русларга тапшырырга вәгъдә иткән. Ары таба Чура Нарыковның хыянәтчел эшчәнлегенә бөртекләп кермичә, аның гаиләсе, хезмәтчеләре һәм сакчылары белән бергә Мәскәүгә качуын, әмма юлда, куып җитеп, хан гаскәре тарафыннан үтерелүен искәртү белән чикләнәбез. Бу хакта татарларда әсирлектә булган исеме билгесез рус авторы «Казанская история» дигән китабында яза, Нарыковның һәм Мәскәү яклы морзаларның 1547 елда Сафагәрәй хан тарафыннан үтерелүе турында башка төрлерәк мәгълүмат та сакланган.

Тартып-сузулар исәбенә Чура Нарыковны акларга тырышкан Фатих Урманчеев ушбу сатлыкҗанның үлемен дә батырлык үрнәге итеп күрсәтергә омтыла, янәсе, үзен куып җиткән хан гаскәре белән (димәк, үз ватаны гаскәре белән!) «нәкъ халык дастанындагыча, тигезсез бәрелештә батырларча сугышып һәлак булган». Бу, әлбәттә, караны ак итеп күрергә тырышуның, кирелек белән бәйләнгән хаталануның кычкырып торган бер үрнәге.

Казанга кат-кат һөҗүм иткән рус гаскәре белән батырларча сугышкан дастан героеның Чура исемле реаль прототибы булганмы – сакланып калган тарихи чыганаклар буенча бу сорауга уңай җавап биреп булмый. Билгеле булуынча Шәриф Хаҗитарханның (бу исем Казан ханлыгының күренекле дәүләт һәм дин эшлеклесе, шагыйрь Кол Шәриф белән тиңләштерелә) безнең көннәргә килеп җиткән «Зафәр намәи вилаяте Казан» дигән тарихи-публицистик әсәрендә 1550 елда татар гаскәренең Иван IV гаскәренә каршы батырларча көрәше тасвирлана. Анда Казанны саклауда катнашкан һәм төп рольне уйнаган барлык батырларның да исемнәре берәм-берәм санап күрсәтелә, әмма алар арасында Чура исемлесе юк. Рус гаскәрләре белән соңгы сугышны тасвирлаган язма чыганакларда да, шулай ук Казанның алынуы турындагы хатирәләрдә дә Чура исеме телгә алынмый, гәрчә аларда батырларча һәлак булган чын геройлар исемләп бирелгән булса да.

Болардан бик мөһим нәтиҗә соралып тора: дастанда тасвирланган Чура батыр образы, безнең карашыбызча, конкрет шәхесне гәүдәләндерми, ул – гомумиләштерелгән җыелма образ. Чынлыкта аның прототибы – Казанны соңгы сулышына кадәр саклаган һәм яу кырында ятып калган дистәләрчә һәм йөзләрчә каһарманнар.

**(Быелның 2-14 август көннәрендә «Тормыш стиле – мәдәни код» II халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать этно-fashion фестивале кысаларында узган "Заманча мәдәниятнең эпик константасы: милли эпосларны саклау һәм популярлаштыру проблемалары" Халыкара конференциясеннән чыгыш)**



# МӨСЛИМЛЕЛӘРДӘН – *халкыбыз хәзинәсенә рухи мирас*

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият*
*һәм сәнгать институтының халык*
*иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

**Экспедиция барышында Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан Мөслим районы авыллары информантларыннан язып алынган кайбер истәлекләрнең дәвамы. Башы журналыбызның 3 нче (2022 ел) санында.**



**Имамовлар гаиләсендә. Баланлы авылы**

## ЮГАРЫ ТАБЫН
*(тарихи-топонимик риваять)*

Монда унсигезенче гасыр башында ишан нәселеннән булган бер кеше үзенең алты улы белән Урал якларыннан килеп төпләнә. Шушы тирәләргә алты улы алты җиргә табын-табын урнашалар, алты җиргә алты табын ясыйлар. Шуның бер улы Түбән Табынны, икенчесе Югары Табынны кора. Бу авыллар үсеп китә. Авыл исеме шуннан. Хәзер 126 хуҗалыклы авыл, 265 кеше яши.

**Хафиз Хәертдин улы ВӘЛИЕВ (1945 елгы), Югары Табын авылы**

## ЛАПАС ИЯСЕ
*(мифологик хикәят)*

Атлы эштә эшләдем. Тычканның ат ялын үргәнен күргәнем булды. Лапас иясе ие ул. Ул төрле сурәткә кереп күренә бит кеше күзенә, күренсә. Матур итеп үргән ат ялын. Ут яндырып кергәч, качып өлгерә алмады.

**Дамир Шамил улы КАДЫЙРОВ (1947 елгы, тумышы белән Югары Табын авылыннан), Түбән Табын авылы**

## ӘБИ ТАВЫ
*(тарихи-топонимик риваять)*

Олы Чакмакны көчле давылдан ишаннар каберлеге саклый, диләр. Әби тавы да саклый аннары. Әби тавы – Урал тавының дәвамы. Екатерина патша белән бәйле, «Әби тавы» дип аталуы, ул шуннан үткән. Элек сугышканнар бит инде берсе белән берсе дин өчен. Әби тавыннан дошман ягына агач тәгәрәткәннәр урманнан кисеп. Урман куе булган монда. Тавы да текә-текә таулар. Олы Чакмак шул тау артында бит инде.

**Фәридә Гыйзетдин кызы ГЫЙЛЬМАНОВА (1927 елгы), Олы Чакмак авылы**

## БАГЫШЛАУ
*(теләк-алгыш )*

Я Аллам! Ут казаларыннан, су казаларыннан, җил казаларыннан, мал казаларыннан сакла! Гомерем булса, ризыкны уңнан бир, сулдан бир, мулдан бир. Әҗәл вакытларым җитсә, аз авыру, ансат үлем бир, пәйгамбәребез өммәтеннән ит. Соңгы сулышымда «Ля иләһа илля Аллаһу» кәлимәсен әйтеп китүләрне насыйп кыйл. Кабер газаплары, тәмуг газаплары бирмә, ләхетләрем чиста урыннарга туры килеп, рәхмәт фәрештәләре каршы алса иде. Лә иләһи! (Мең мәртәбә шулай әйтәм). Җәннәтеңне насыйп ит.

**Фәридә Гыйзетдин кызы ГЫЙЛЬМАНОВА (1927 елгы), Олы Чакмак авылы**

## КЫЗ УРЛАП ӨЙЛӘНҮ
*(йола элементы)*

Кыз урлау бар иде элек. Ошатсаң, өйләнәм дисәң, синең теләккә каршы хәлләр чыгып торса, тотасың да урлыйсың. Ат җигеп әзерләнеп киләсең, уңайлы вакытта күтәреп китәсең, чанага саласың да алып кайтасың. Бер кайткач, ычкына алмый инде, яшәп кала. Муллага әйтеп куелган була, никах укытасың.

**Сабирҗан Хафиз улы ХАФИЗОВ (1940 елгы, тумышы белән Симәк авылыннан), Шуганка авылы**

## ҖЫРЛА ДИСЕЗ

Кычкырып җырлау хәрәм диләр
Мөхәммәд өммәтенә,
Җырламый да булмас инде
Сез дуслар хөрмәтенә.
Камалы тун, кара бүрек
Бай баласы башында,
Ниләр дип җавап бирербез
Хак тәгалә каршында?

**Рәфкать Сәгыйть улы КӘРИМОВ (1930 елгы), Тәйгелде авылы**

## ТУФАН СУЫ
*(мифологик истәлек)*

Туфан суы калкасы икән. Бөтен дөньяны каплыйсы. Бөтен нәрсә су эчендә калачак. Шулай дип сөйлиләр иде дә, кайчан калкыр туфан суы дип йөргән чаклар бар иде бала вакытта.

**Илисәй Имам улы ИМАМОВ (1932 елгы), Баланлы авылы**



## ӘТӘЧ БАШЫ КЫСЫЛГАН
*(мичче кыйссасы, мәзәк хәл)*

Мич чыгаручыны сыйлый торган булганнар бит инде. Сыйламасалар, мичче каһәгать калмый. Ачуы килсә, мичнең морҗасын өеп бетергәндә иң өскә пыяла куеп калдыра. Төтен юлын каплый торган итә үч итеп саран хуҗаларга. Мич әзер була. Мичче китә. Хуҗалар мичкә ягып җибәрәләр. Өй төтен белән тула. Мич суырмый. Астан карыйлар – яп-якты, бер нәрсә капламый, хуҗалар эшнең нәрсәдә икәнен һич белмиләр. Аптырагач, кабат миччене чакыралар. Әтәч суеп, сыйлыйлар миччене, тиешлесен биреп бетерәләр моңа. Шуннан мичче морҗа өстеннән бер кирпеч ватыгы ташлый, куеп калдырылган пыяла ватыла, шуның белән мәсьәлә хәл ителә.

– Әтәч башы кысылган булган! – дип төшә мичче. Менә шулай, әтәч суеп сыйламый торып, мич суырмый. Читләтеп шулай әйтеп кую бар. Яңа мич тартмый торса, әйтәләр:

– Әтәч башы кысылганмы әллә? – диләр.

**Фәиз Габдрахим улы БИКТАШЕВ (1965 елгы), Метрәй авылы**

## ПУЛЯ ЯВА МОНДА!
*(Фольклорда эпистоляр жанр)*

Одеял ябынасыңмы,
Юрган ябынасыңмы?
Сугышларда ялгыз башың
Безне сагынасыңмы?

Ире Кыяметдингә хатыны Мәрҗәм хат язган шулай дип. Кыяметдин шаян кеше булган, уенын-чынын бергә кушып, болай дип җавап язган:

Одеял да юк монда,
Юрганы да юк монда,
Яңгыр урынына пуля ява, кибиниматри!
Сезнең кайгы юк монда!

**Тихния Фатих кызы КӘРИМОВА (1934 елгы), Тәйгелде авылы**



**Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Мөслимдә комплекслы фәнни экспедициядә. 2017 ел**

## САЛЧЫЛАР АВЫЛЫ
## ҺӘМ ҖИДЕ МӘХӘЛЛӘ

*(тарихи-топонимик хикәят)*

Әбекәй Салауз Муханга Мортыштан (Сарман районы) килгән. Килен булып төшкәч, бабакай кер чайкарга аны Ыкка озатып куя торган булган. Монда нык калын карурман булган әлек. Агач кискәннәр дә сал агызганнар. Салчылар яшәгән монда. Авылда җиде урам булган. Җиде урамның кайсы буйлап китсәң дә юл мәчеткә алып килә икән. Берәү монда читтән килеп адашкан, төрле урамга кереп чыга икән, һаман мәчеткә китерә ди юлы. Бу әйткән:

– Җиде мәхәлләле авыл икән бу, – дигән.

**Рамилә Мисбах кызы КАШАПОВА (1959 елгы), Салауз Мухан авылы**

## КҮЧТӘНӘЧ ЧЫГАРУ ҖЫРЛАРЫ

Ипекәй дә, җирән лә ай, атыгыз,
Аның берсен безләргә сатыгыз.
Бу кадәрле күп күчтәнәчне
Ничек тартып килде лә атыгыз.
Күк күгәрченнәренең сөтен саудым
Казан прәниге ясарга.
Бик күп күчтәнәчләр китергәнсез
Кардәш-ыру белән ашарга.
Безнең атларыбыз бик бәләкәй,
Бәләкәй булса да калынча.
Безнең күчтәнәчләр зурлар түгел,
Кабул итегезче барынча.
Көмешләрме сезнең акчагыз,
Бакырлармы сезнең акчагыз.
Көмеш булса алып куярбыз,
Бакыр булса алып шуарбыз.
Усы буйларының тегермәне
Җалан гына бодай тартадыр.
Безнең атларыбыз шулай яхшы,
Нилә салсаң шуны тартадыр.
Киемчеләр киемнәр ай кисәдер,
Кала микән аның почмагы.
Кулларыгызны талдырып сез тормагыз,
Әнә сезгә өстәлләр почмагы.

**Елизавета Алексеевна МИТЮШКИНА (1978 елгы), Сөмбел Мөхәммәтхафиз кызы ГРИГОРЬЕВА (1977 елгы), Яңа Усы авылы**

## КАЕНСАЗ АВЫЛЫ

*(топонимик хикәят)*

1903 елда Иске Айманнан күчкән авыл бу. 60 семья килгән монда. Бер ел эчендә күчеп беткәннәр. Яртысы мари, яртысы – татар. Әхмәди нәселе килә татарлардан, Галим нәселе, башкалар тагын. Монда аннан алда да кешеләр яшәгән. Мазаркага зиярат кылырга барганнар. Кыпчак, бәҗәнәкләр, җәмәк, башкортлар яшәгән монда. Бу урында каенлык, сазлык булган. Шуңа «Каенсаз» дип атаганнар. Землемердан болынлык сораганнар безнекеләр җир бүлгәндә, теге әйткән:

– Бер тавык та бер савыт! – дигән. Безнекеләр бирмәгән. Шуңа сазлык тигән.

**Мөнәвис Әхмәткәрам улы ШӘЙКӘРАМОВ (1938 елгы), Каенсаз авылы**

## НӘҮРҮЗ

*(йола фольклоры)*

– Нәүрүзгә ярма җыябыз! Бәйрәм белән! – дип килеп керәләр балалар.

Ярмалар, күкәйләр җыеп, клуб каршында пылау пешерәләр. Төрле уеннар үткәрәләр, җырлыйлар, бииләр.

Нәүрүз бәйрәме элек үткәндер ул, аннан туктап торгандыр. Кабат үткәрелә башлавы 1995 елларга туры килә. Нәүрүз – кыш белән язның очрашуы, язның җиңүе белән тәмамлана. Карачкы яндыралар. Авыл халкы җыела.

**Фаягөл Нуретдин кызы ГАЙНЕТДИНОВА (1946 елгы), Татар Шураны авылы**

## КРАСНОЯР АВЫЛЫ

*(тарихи-топонимик риваять)*

Елгабаш авылыннан урман әчләтеп бирегә күчеп утырган крестьяннар авылга нигез салган. Хуҗалыкларын арттыру максаты белән җиде нәсел килгән монда. Милли составы ягыннан гел татарлар гына булган. Элекке переписьләр буенча милләтне белеп булмый, чөнки сословиеләр күрсәтелгән анда. Чынлыкта монда татарлар яши электән. Авылны башта «Яңа авыл» дип йөрткәннәр. 1925 елда авыл исеме табыла: авыл башындагы кызыл яр янында землемер авыл исемен сорый, авыл кешеләре «Яңа авыл» дип йөртәбез дигәч, «Русчасы ничек була?» – дип сорый. Шуннан кызыл ярга карый да «Красный Яр» дип язып куя. Шуннан бирле авылны «Кызыл Яр» дип тә, «Краснояр» дип тә йөртәләр.

**Миңнулла Габдулла улы АБДУЛЛИН (1944 елгы), Краснояр авылы**

## КАРГА БОТКАСЫ

*(йола фольклоры)*

Нәүрүз элек юк иде. Карга боткасы – электән. Көн буена урманда ята иде авылның бөтен баласы. Урманда казан асып ботка пешерү була торган иде.

– Ак түтәй, бер күкәй! – дип керә бала-чага.

– Исән-имин үткәрегез! Менә күкәйләр, менә ярма! Тәртипле булыгыз! – дип әйтеп бирәләр.

**Гөлүсә Шәях кызы ХӘЛИУЛЛИНА (1946 елгы, тумышы белән Актаныш районы Чуракай авылыннан), Яңа Карамалы авылы**

## БИК ЧАБА АЛМАССЫҢ!

*(Мәзәк)*

Бер урыс килгән авылга. Юл сорый икән. Авыл кешесе аңлата моңа:

– Менә шулай таба китәсең. Дебер-дебер чыгарсың, әзрәк баргач умирал, – дип аңлата ди күпер чыккач зиратны үтәсе дигәнне.

– Чего? Чего? – дип сорый икән берни аңламаган урыс.

– Бик чаба алмассың. Аннан соң байтак кына үр менәсең бар әле, – дигән ди агай.

**Бания Хәйдәргали кызы БОРҺАНОВА (1946 елгы), Әмәкәй авылы**

## ӨЙ ИЯСЕ КЕМ ДӘ АЛБАСТЫ КЕМ?

*(Мифологик хикәят)*

Җен күргән бар минем. Күренә дә юк та була. Мин кәтү көттем, колхоз кәтүе. Сыерларны тупладым да яттым бервакыт. Яланда таулырак җирдә үләт базы бар иде. Эт булып барды-барды да төште дә китте базга. Ап-ак эт. Җен бөтен кыяфәткә дә керергә мөмкин бит ул. Албасты – анысы зур эш инде, анысын без белмибез. Албасты – шул җеннәр башлыгыдыр ул. Өй иясе – әнә ул бар. Ул ничек? Казанга барганыем, бульниска. Бер абзыйларда кундым. Өй ияләре мине караваттан сүрәп төртә дә төшерә, төртә дә төшерә. Чыктым да бирандыга яттым. Бүтән тегендә кермәдем. Өй иясе ул әшәке дә, яхшы да түгел, өй хуҗасы инде. Абзарның да була иясе. Үрә ялын атның, үрми ул аны, чурый да чурый, чурый да чурый. Абзар иясе, яратмаса, атны тукмай. Ат иртәнгә арып беткән була. Абзар хуҗасы диләр анысын.

**Миргазыян Исмәгыйль улы ИСМӘГЫЙЛЕВ (1939 елгы), Исәнсеф авылы**

## КУНАК ОЗАТКАНДА

*(теләк-алгыш)*

Ак мыек, ак мыек,
Бер-беребезне какмыек,
Каккан-суккан җирләр булса,
Бер-беребезне яклыек.

**Зәйтүнә Нәҗметдин кызы ИСМӘГЫЙЛЕВА (1936 елгы), Исәнсеф авылы**

## СИМӘК

*(тарихи-топонимик хикәят)*

Симәкнең тарихы Иван Грозныйдан ук килә аның. Яу килгәч, ике мең кеше, чолганыштан чыгып, борчак кебек тарала. Шулардан бер нәсел монда, Симәккә килеп урнаша. Симәкнең борынгы шәҗәрәсе саклана.

**Мансур Дакариевич ХАРИСОВ (1963 елгы), Симәк авылы**

## МӨСЛИМ – БАЗАРЛЫ ВӘРӘШ

*(тарихи риваять)*

Унсигезенче гасыр башында Мөслим «Базарлы Вәрәш» дип аталган. Әлек базар булган монда. Эре базар. Әмәкәй, Русский Шыдан (Атай Күл), Ольгина (Иштирәк) базарлары кебек базар булган Базарлы Вәрәш. «Базарлы Вәрәш» дигәннәр шуңа күрә. Шуннан Иске Вәрәшкә җиде кеше килеп утырган, шуның берсе Мөслим исемле булган дип сөйлиләр. Ыкның теге ягына күчеп йорт салган Мөслим. Бүгенге Мөслим аның исеме белән аталган.

**Равил Илдар улы ТИМКИН (1985 елгы, тумышы белән Казаннан), Вәрәшбаш авылы**

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

# ИЗГЕ ТЕЛӘК
# *тели белик*



*Илсөяр ЗАКИРОВА,*
*филология фәннәре докторы,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел,*
*әдәбият һәм сәнгать институтының*
*халык иҗаты бүлеге баш фәнни*
*хезмәткәре*

**Татар фольклорында бүгенгә кадәр аз өйрәнелгән, яки әлегә кадәр галимнәрнең игътибарыннан читтә калып килгән жанрлар бар.**

**Шуларның берсе – алкышлар. Бу жанрга караган әсәрләр татар паремияләре составында фольклор җыентыкларына кертелсә дә, әлегә кадәр алкышларның аерым фәнни тикшерү объекты булганы юк. Жанр татар фольклорында, башка төрки халыклардагы шушы ук эчтәлекле әсәрләр кебек үк, алкыш термины белән атала.**

Шулай ук телдә «теләк», «изге теләк» дигән гыйбарәләр дә очрый. Контексттан чыгып, «хәер-фатиха» терминының да алкышка туры килүе күзәтелә. Хәер-фатиха бер яктан өлкән, хөрмәтле кешенең зур эшкә, мәсәлән, гаилә корырга, яңа эш башларга, яшәү урынын алыштыруга, күчеп китүгә һәм башкаларга рөхсәтен аңлатса, икенче яктан шушы эш-гамәлгә бәйле изге теләкләре, догасы да. Алкышлар берничә сүздән генә торган кыска текстлар да, берничә строфадан торган шигъри әсәрләр дә булырга мөмкин. Гаилә йолалары вакытында башкарылган арбау жанры да эчтәлеге һәм функциясе белән алкышларга якын.

Алкышларның нигезендә сүзнең магик көченә ышану, яхшы сүз ярдәмендә кешенең тормышына уңай тәэсир итәргә омтылыш ята. Татар халкында «Кеше теләге кешегә кабул була, ди» дигән ышану да бар. Алкышлар борынгы жанрлардан булып, аларның текстларына яки башкарылуына бәйле мәҗүсилек чорына караган элементлар саклана. Идел буенда Ислам дине кабул ителгәннән соң алкыш текстларында ислам дине белән бәйле образлар, мифологик ышанулар урын ала.

Бу текстлар төрле шартларга һәм вакыйгаларга, эш-гамәлгә, йолаларга бәйле рәвештә башкарыла. Башкарылу үзенчәлегенә карап татар фольклорында һәм телдә сакланып калган алкышларны төп ике төргә бүлеп карарга мөмкин. Беренче төр алкышлар көнкүрештә әйтелә. Алар күләме белән кечкенә, берничә сүздән тора һәм, кагыйдә буларак, тотрыклы текстлар. Үзгәрә ала торган текстлар да аерым кагыйдәләргә буйсына. Икенче төр алкышлар календарь яки гаилә-көнкүреш йолалары составында башкарыла торган текстлар. Күпчелек очракта алар берничә юлдан торган тезмә әсәрләр.

Көндәлек тормышта әйтелә торган алкышларны үзләрен дә ике төргә бүлеп карарга мөмкин. Беренчесе берәр вакыйга, эш-гамәлгә карата изге теләк рәвешендә әйтелсә, икенчесе берәр гамәлгә яки бүләккә каршы рәхмәт буларак әйтелә. Беренче төргә караган, татар халкында еш кабатлана торган алкышларга түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин.

Эш белән бәйле текстлар кешенең ниндидер эш эшләгән вакытында әйтелә. «Алла куәт бирсен!» яки «Алла ярдәм итсен!», «Җиңеллеген бирсен!» Эшләүче кеше җавап буларак рәхмәт әйтә, «Сине дә безгә бирсен» дигән, шаярып әйтелгән җавап та очрый. Татар телендә «Алкыш алган арымас» дигән мәкаль бар. Ул хезмәткә карата әйтелә торган текстларның магик көченә ышануны күрсәтеп тора.

Кешенең өенә кереп, аш вакытына туры килгән кеше: «Ашыгыз тәмле булсын!», «Чәегез тәмле булсын!» дигән теләк әйтә. Җавап рәвешендә «Бергә булсын!» дип, килгән кеше дә табынга чакырыла. Татар халкында чит кеше өенә кергәннән соң, йорт хуҗаларына изге теләкләр теләп дога кылу күренеше соңгы ун-унбиш ел эчендә юкка чыгып бара. Егерме ел элек татар өенә кергән кунак, исәнләшкәннән соң, «Ягез, бер дога» дип өй хуҗалары белән утырып дога кылган, йортка теләк теләгән, шуннан соң гына йомышын әйткән. Кунаклар өстәл янынннан торганда да, ризык-сый өчен рәхмәт әйтеп, дога кылалар, теләк телиләр. Бу теләкләр шактый күләмле тексттан гыйбарәт. Анда йорт хуҗаларына, балаларына бәхет, иминлек, малларының артуын телиләр.

2016 елгы экспедиция вакытында Алтай өлкәсе Угловский районының Бөкер авылында Фатыйма Нургата кызы Баһавиевадан берничә алкыш язып алынды. Бу текстлар татар фольклор җыентыкларында теркәлмәгән булу сәбәпле, аларны тулысынча бирәбез.

**АЛКЫШЛАР**

*Гомерлек мәхәббәт бирсен,*
*Бетмәс дәүләт бирсен,*
*Акылларыгыз ашсын,*
*Бәхетләрегез ташсын,*
*Һич яманлык булмасын,*
*Аман булсын йорт-җирләрегез,*
*Алла Тәгалә диннәрегезгә саулык бирсен,*
*Дәстәрхәнегезгә байлыгын бирсен,*
*Ахирәттә иман бирсен,*
*Терелектә тәүфикъ бирсен,*
*Бирәхмәтикә*
*Йә әрхәмәр рахимиин.*
*Илаһи, амин! Илаһи, амин!*
*Аллаһ әкбәр, амин,*
*Аллаһ әкбәр, амин.*

*Чәегез кызыл булсын,*
*Гомерегез озын булсын,*
*Дәүләтегез таша бирсен,*
*Дошманыгыз кача бирсен,*
*И Ходаем, үзегезгә озын гомер яза бирсен.*
*Илаһи, амин! Илаһи, амин!*
*Аллаһ әкбәр, амин,*
*Аллаһ әкбәр, амин.*

*Бисмиллаһи рахман ирраһим,*
*Йа рабби, Ходаем,*
*Безнең хушыбызга керешеп,*
*Безнең арабызда йөрерлек булсын,*
*Йа рабби, Ходаем,*
*Тынычлык белән, хәерле ризык белән,*
*Хәерле тормыш белән,*
*Йа рабби, үзләребезгә,*
*Мал туарларыбыз аман булып,*
*Йортларыбызга сәламәтлек биреп,*
*Сабырлык белән яшәргә насыйпка*
*ирештерсен,*
*Илаһи, амин! Илаһи, амин!*
*Аллаһуммәгъфирли,*
*Фәгъфирли,*
*вәли-вәлидәйнә,*
*вәли җәмигол мөэминине*
*вәл мөэминәт,*
*вәл мөслиминә вәл мөслимәт,*
*вәл моңзиләл бәрәкәт,*
*вә рафигад-дәрәҗәт,*
*вә казиел-хәҗәт.*
*Амин.*

*Бирәхмәтикә йә әрхәмәр рахимиин.*
*Илаһи, амин!*
*Илаһи, амин, илаһи, амин!*
*Аллаһ әкбәр, амин,*
*Аллаһ әкбәр, амин.*

Татар халкы Ислам динен рәсми рәвештә X гасырда кабул итә. Шул вакыттан белем бирү системасы формалаша, мәктәп-мәдрәсәләр ачыла. Мәдрәсәдә, матди хәленең ничек булуына карамастан, һәр бала белем ала. Халык укуга бит җитди карый, әмма мәдрәсәдә белем алу балага җиңел бирелми. Татар халкында баланың шушы авыр бурычын изге теләк ярдәмендә җиңеләйтүгә юнәлтелгән алкышлар, теләкләр формалашкан. Бу төр алкышларга түбәндәге мисалларны китерергә мөмкин: «Ходай тел ачкычлары бирсен!», «Укытучыларың/остазларың күзенә сөйкемле күрен!», «Башыңа зиһен бирсен!». Әлеге текстлар хәзер дә актив кулланылышта.

Алкышларның бер төре бүләк өчен рәхмәт рәвешендә әйтелә. Ягъни кеше үзенә карата эшләнгән яхшылыкка яки бирелгән бүләккә каршы алкыш әйтә. Бу очракта алкыш җавап бүләкнең/рәхмәтнең эквиваленты булып тора. Мәсәлән, кешегә эш белән ярдәм иткәч, «Аяк-кулың сызлаусыз булсын!» дигән теләк әйтелә.

Эш өчен рәхмәт әйтеп башкарылган алкыш мисалы татар халкының «Ак Көбек» дастанының бараба вариантында сакланган. Ак Көбек үзенә корал ясаган остага рәхмәтен алкыш белән белдерә:

*Торга путсун бу җирдән-әй!*
*Камга путсун бу җирдән-әй!*
*Ишегеңнән тәк инсен-әй!*
*Төнлегеңнән тәк төшсен-ай!*
*Адың-елгыс бай булсын!*
*Баеп-череп үлерсең!*
*(Затлы ефәк булсын бу җирдә-әй!*
*Кытай ефәге булсын бу җирдә-әй!)*
*Ишегеңнән бәхет инсен-әй!*
*Төнлегеңнән бәхет төшсен-әй!*
*Атың-елкың бай булсын,*
*Баеп-череп үләрсең!*[1]

Ярдәм күрсәтүченең яшь үзенчәлекләре, гаилә хәле һәм башка яклары истә тотылып, һәр конкрет очракта туры килгән теләкләр дә әйтелә. Мәсәлән, балага карата «Тәүфикълы бул, тигез канатлы – ата-аналы булып үс!» дигән теләк, уку яшендәге бала өчен алдарак әйтелгән теләкләр әйтелсә, гаилә кору яшенә чыкканнар өчен «Хәләл ана сөте эчкән яр насыйп булсын!» «Тигез мәхәббәт бирсен!» дигән теләкләр бар.

Пермь өлкәсендә узган экспедиция вакытында алкышларның тагын бер төре язып алынды. Аларны информант «әби-бабайның тиргәшкәне» дип атый. Алар баланың берәр ярамаган эшен күргәндә, кисәтү урынына да әйтелергә мөмкин. Аларда да сүзнең магик көченә ышану ята: «Әй, кызым, балам, бәхетең арткыры, акча тапкыры, сөйкемле булгыры, телең баллы булгыры». Андый алкышларның кешегә яки гаиләгә байлык, иминлек теләгәннәре дә бар. «Икмәгең чапчагыңнан артып чыккыры, мичтә ипиең кызарып пешкере, айраның күп булгыры, сыерың сөтле булгыры, ике бозау тапкыры»[2].

Хәзерге вакытка кадәр яхшы хәбәр китерүчегә, яхшы сүз әйтүчегә карата «Авызыңа бал да май» дигән алкыш әйтәләр.

Әлеге алкышлар көнкүрешкә, көндәлек тормышка бәйле рәвештә әйтелә. Алар җыйнак текстлар. Шартлы рәвештә бу текстларны «Көнкүреш алкышлары», яки «Теләкләр» дип атарга мөмкин. Көнкүреш алкышлары ритуал-йолалар вакытында да кулланыла, алар универсаль әсәрләр.

Икенче төр алкышлар аерым йолаларга бәйле рәвештә башкарыла. Алар күләмнәре белән зуррак, тотрыклы шигъри текстлар. Аларны шартлы рәвештә «йола алкышлары» дип аерабыз. Аерым йола белән бәйле алкышлар, бары шул йола вакытында гына башкарыла. Календарь йолалар белән бәйле алкышлар аерым кешегә генә түгел, илгә, халыкка имин тормыш теләүгә юнәлтелгән. Мәсәлән, Нәүрүз, Нардуган, Карга боткасы кебек календарь бәйрәмнәрдә һәр йортка кереп бәйрәм боткасы өчен ризык яки бәйрәм уңаеннан бүләк җыючылар рәхмәт әйткәндә алкыш әйтәләр:

[1] Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар. – СПб., 1872. – С. 48.
[2] Пермь өлкәсе, Уин районы Чәйкә авылында Фәйхүнә Шаһинур кызы Әҗмухановадан (1940 елгы) автор тарафыннан язып алынды.





**Уртада информант Фатыйма Баһавиева. Алтай өлкәсе, Угловский районы, Бөкер авылы**

*Мал-туарыгыз артсын,*
*Колыннарыгыз чапсын,*
*Игеннәрегез уңсын,*
*Күкәй кебек тук булсын!*[3]

Гаилә йолалары вакытында башкарыла торган алкышлар да бар. Яңа туган балага, яңа гаиләгә коручыларга атап әйтелгән алкышларда аларга бәхетле имин гомер теләнә. Яңа туган балага карата иң еш кабатлана торган алкыш: «Тулы бәхете, тәүфигы, үз ризыгы белән килсен!». «Кешене ризыгы йөртә» дигән мәкальдән аңлашылганча татар халкында ризык ашамлык мәгънәсендә генә кулланылмыйча, язмышны да аңлата. Шулай ук баланың тәрбияле булуын, әхлак ягыннан камил кеше булып үсүен, ягъни тәүфикълы булуын телиләр.

Туй йолаларында яшьләргә тигез мәхәббәт, тигезлек, күп бала телиләр: «Ал итәгеңне бала бассын, арт итәгеңне мал бассын!» Туй йолалары вакытында башкарыла торган арбау жанры да эчтәлеге белән алкышларга якын. Арбаулар сүз ярдәмендә киленне яңа йортына бәйләү өчен башкарылган. Аларда да киленгә, яңа гаиләгә бәхет теләнә:

*Төкле аягың белән, таймас кулың белән,*
*Таймас табаның белән кил!...*
*Эшең, көнең уң булсын,*
*Ашың, суың мул булсын!*[4]

Арбауларның алкышлардан аермасы шунда – аларда магиягә басым ясала, сүз ярдәмендә кешенең тормышына магик тәэсир итәргә омтылыш ята.

Алкышлар татар фольклорында шактый күп санлы жанр булып, бүгенгә кадәр махсус өйрәнелмәгән. Аерым текстлар язып алынган очракта да, башка жанрлар, мәсәлән йола фольклоры составында гына язып алынган. Соңгы елларда узган экспедицияләр бу жанрга караган әсәрләрнең хәзер дә телдә саклануын күрсәтә. Бу жанр халыкның менталь кыйммәтләрен ачыклау ягыннан да, милли этикетны өйрәнү өчен дә әһәмиятле чыганак булып тора. Алкышларда җәмгыять һәм гаилә кыйммәтләре, гомумкешелек өчен мөһим әхлакый кыйммәтләр алга чыга.

[3] Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары / Томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Надиров И.Н. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 46.
[4] Шунда ук. – Б. 158.

Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

# Яңа китап


**2002 елда «Казан утлары» журналында «Албастылар»ның беренче ике бүлеге басылып чыккан иде. Флүс Латыйфи белән Мансур Вәлиев аның жанрын хыялый кыйсса дип билгеләделәр. Кыйсса әдәбият сөючеләр арасында да, гыйльми даирәләрдә дә зур кызыксыну уятты. Әсәр басылып чыккач та, дәвамын сорап, татарлар яши торган төбәкләрдән хатлар килә башлады, хәтта күмәк мөрәҗәгатьләр дә булды.**

«Албастылар» 2003 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Тиз арада сатылып бетте һәм кулдан кулга йөри торган бестселлер китапка әверелде. Ике дистә ел буе филологик вузлар программасында өйрәнелүен дә исәпкә алсак, китапка ихтыяҗның зур булуы аңлашыла. Китап кайткан авылларда клубка җыелган халык алдында әсәрне кычкырып уку очраклары да билгеле. Егерме ел эчендә укучылардан биш йөздән артык хат-мөрәҗәгать килде. Күпләр кыйссаның дәвамын иҗат итүне сорап язды, хат авторлары, хәтта, сюжет үстерелеше өчен, үз идеяләрен, язмыш тарихларын тәкъдим итә башладылар.

Минем иҗатны үз күргән игелекле укучыларыма җавап итеп, 2020-2021 елларда «Албастылар» кыйссасының дәвамын иҗат иттем. 2020 елда Татарстан китап нәшриятында кабат басылган беренче китап ахырында, кызыксындыру йөзеннән, икенче китаптан өзек урнаштырдым. Шул өстәмә бүлек белән танышкан укучыларым әсәрнең дәвамын тулысынча бастыруны сорап мөрәҗәгать иттеләр. Шушы көннәрдә «Албастылар-2» китабы Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде.

* * *

Әсәрне укып чыгу белән, укучыда: «Дәвамы булырмы?» дигән сорау туарга мөмкин. Бу сорауга хөрмәтле Укучым үзе җавап бирергә тиеш. Хәзерге татар тарихының кискен бер чорын




тасвирлаган, кара урман төпкелендәге татар авылында барган серле-шаукымлы вакыйгалар кызык тоелса, бу вакыйгалар эчендә кайнаган герой-каһарманнарның язмышы кайсы тарих борылмаларына кереп китүен күзәтергә теләсә, Укучым турыдан-туры авторга мөрәҗәгать итә ала, хәтта үзенең идеяләре, сюжетлары белән уртаклаша ала. Әсәр тукымасына матур гына кереп киткән Юламан карт образы, Давыл белән Җавыл дигән серле урман затлары укучылар белән аралашудан соң туган иде бит! Андый хыялый-шаукымлы затлар, мотивлар хакында шуны гына әйтә алам: Укучым аларны күңеленә якын алмасын, халкыбызның мәдәни мирасыннан алынган кадерле рухи ядкәрләр яисә хыялый кыйссаларны төзүдә үтә дә мөһим әдәби һәм поэтик алымнар буларак карасын иде. Әсәрдә иң мөһиме – хәтер кайтару һәм ыру, нәсел, гаилә культы белән бәйле фикерләр. Ахыр чиктә нәкъ менә шушы тәгълиматлар татарның милли идеясен тәшкил итә дә инде.

**Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,**
**язучы**



# Албастылар

**(Хыялый кыйсса. Икенче китаптан өзек)**

...Иртән уянганда Нәфисәнең күкрәк баласы тынсыз-өнсез булып торды. Өйдәгеләр сабый бишегә тирәсенә җыелдылар. Хәят ни тере, ни үле иде. Бөтен тәне кызышып яткан баланың сулышы «әчкә киткән» иде. Сулыш алып та, тынын тышка чыгара алмаган кешеләргә халыкта шулай диләр. Болай кысылган сулыш белән озак яши алмаячак ул. Барысы да, чиратлашып, колакларын сабыйның йөзенә якын ук китереп, аның сулу алуын тикшереп чыктылар. Һәркем үзенчә фикер йөртте. Сания сүзен ерактан – табигать шаукымыннан башлады:

– Кичә урман ягыннан «аҗун» җиле исеп алган иде, хәтерлисезме, кеше ыңгырашкан тавышлар чыгарып килде ул. Аннары, лапас тирәсендә мыгырданып ятты да, шулай ук ыңгырашып, кабат урманга китеп тә барды. Менә шуннан гына күрәм. Ул килгәндә Хәятыбыз ихата уртасындагы арбасында ачылып ята иде... Йөгереп барып өстен япканчы, теге аҗун зәхмәтләре балакайны сыйпап үткән булган инде...

Тәскирәнең үз ырымы:

– Аҗун дисең син, Саниякәй. Җил ул исә дә китә... Аның шаукымы озакка бармый. Менә мин төгәл күреп калдым: кечә бу тирәдә бер кара мәче борталанып-сыргаланып йөрде. Бер-ике мәртәбә куып та җибәрдем әле. Берсендә менә шул зәхмәт сыңары Хәятыбызның өстеннән үк ыргып үтте. Кара мәче бала өстеннән сикерсә, зәхмәт тия дә тия инде...

Шулай берсеннән берсе уздырып, сәбәпне сихердән, зәхмәттән, күз тиюдән эзләделәр. Үзләренчә имләп, дәвалап, сабыйның хәлен җиңеләйтмәкче булдылар... Тәскирә бишек тирәсендә: «Үткече булсын! Үткече булсын!» – дип бөтерелгән арада Сания, ишек яңакларын, ишек тоткаларын, тәрәзә өлгеләрен су белән чайкап, шул суны бишек катына бөркеп, Хәятны тиешле әфсен белән имләде: «Ай кайтсын, көн кайтсын, кара күз кайтсын!» Суның калган өлешен бусага аша тышка сибеп җибәрде: «Име-томы шул булсын, начар күз җиргә сеңсен!»

Ләкин әфсеннәр дә, ырымнар да ярдәм итмәде. Бала тәнендәге кызу басылмады, аның сулышы да иркенәймәде. Нәфисә әнкәләре башкарган йолаларга карап утырды-утырды да, йөзен каплап, кычкырып елап җибәрде:

– Хәлим дә юк ичмаса-а-ам!.. Аңа ничек җавап бирерме-е-ен?!.

Тәскирә аңа шундук бармак янады:

– Тс-с-с! Кайгы чакырып, елап утырмасана! Бар, Мәймүнә карчыкка йөгер, бәлки аның кулы килешер...

Аны Сания бүлде:

– Мәймүнәне белмим, мәгәр Мәдинәттәй белән Ак бабай керсәләр, барыбер нидер киңәш-табыш итәрләр иде... Әллә шуларга гына керәсеңме, түбән очтагы сихерче карчыкны эзләп йөргәнче...

Озак та үтмәде, Нәфисә икесен дә ияртеп кайтып керде.

Картлар эшнең нидә икәнен шундук аңлап алдылар. Ак бабай Мәдинә карчыкка юл куйды. Тегесе идән уртасына матчага асып куелган бишектә яткан баланың биләвен чишеп җибәрде, аның эчен, күкрәк турыларын капшап, хәтта баскалап карый башлады. Тәнендә чит кеше кулы тойган сабый шыңшып елап җибәрде, авызындагы имезлеген дә теле белән төртеп төшерде... Мәдинә карчык үзалдына гына әйтеп куйды:

– Елый, елагач, яшәүгә өмет бар...

Бала елавына да игътибар итмичә Мәдинә карчык баланы шактый әвәләде әле. Аннары, аны кабат төрә-төрә:

– Балага кату булган. Йөрәге дә дөрес эшләми, сулышы да тарайган... Нәрсәдер балакайның яшәүгә юлын бүлмәкче... Кем, нәрсә – һич әйтә алмыйм. Анысы минем өчен мәгълүм түгел. Бер генә нәрсә әйтә алам: бу авыру гына түгел. Шуңа күрә йә бик көчле имче, йә чын табиб кирәк бу балага. Ә хәзергә... булышса да, әнкәсенең сөте булышыр...

– Алмый бит, имине алмый, Мәдинәттәй!.. – дип, ачыргаланып кычкырганын сизми дә калды Нәфисә.

– Алмаса да эчерегез. Иреннәренә тамчылап тамызыгыз... Ана сөте бит ул, аннан да шифалы әйбер була димени?!

Шулай иттеләр дә. Нәфисә тиз генә сөтен савып бирде. Тәскирә бал кашыгы белән Хәятның авызына сөт тамызырга кереште. Ләкин бала барыбер карышты – сөт тамчыларын авызына алмыйча, ирен читеннән читкә агыза торды... Хатыннар шулай бераз юангач, читтәрәк үз догаларын укый-укый, тыйнак кына басып торган Ак бабай сүз башлады:

– Сания, Тәскирә, күбрәк сезгә әйтәм: табиб чакыртырга кирәк. Врачсыз булмый монда. Баланы карап торып гүргә кертәбез бит...

– Хәзер каян табасың аны, Ак бабай? – Нәфисә Ак бабайның тәкъдимен тыңлап та бетермәде, кул гына селтәде. – Авылда медпунктның ябылганына ике ел бит инде... Бу тирәдә машиналы кеше дә юк, ичмасам... Хәзер җилтерәтеп алып китәр идек районга...

– Нишләп булмасын, бар ул машина, урман буенда арлы-бирле йөрүче полиция машинасы. Кемдер сөйләп торды: төрмәдән качкан кешеләрне сагалыйлар, имеш. Милиция башлыгы да шунда ди... Үзе постлар урнаштырып йөри икән... Аларның барыбер районга кайтасылары бардыр. Кайтмасалар, күрше авылда фельдшер бар, шуны алып килсеннәр...

Иң яше булгач, урман читенә Нәфисә йөгерергә тиеш иде... Ул бер әнисенә, бер Саниягә карап алды да, аларның ияк кагып хуплауларын күргә, бәрелә-сугыла ишектән чыгып йөгерде.

...Нәфисә барып җиткәндә Морад термостан кавырсын стаканга чәйме, кофемы агызып тора иде. Шул агызган килеш, термостагы чәен җиргә түгеп бетерде, ахры, ул...

– Син?.. Майя?.. Каян килеп чыктың, син бит урманда... Чәчеңне кай арада акка буядың?

Нәфисәнең үз хәле хәл иде. Ул урман буенда Майяның әтисен күрермен дип һич уйламаган иде.

– Морад агай? Сез дә мондамыни?

– Сез кем? Майя түгел, монысын чамаладым...

– Майя түгел... Мин – аның туганы Нәфисә... Оныттыгызмыни? Озак аңлатып торырга вакытым юк. Анда минем күкрәк балам – Хәятым үлеп ята. Врач кирәк, аның хәле бик авыр... Тизрәк машина белән ярдәм итегезче... Йә врачка илтегез, йә врачны алып килегез... Зинһар, Морад агай, Сез бит ят кеше түгел... Үземнең газиз сабыем өчен сорыйм!..

Ниһаять, Морад үз каршында Майя булмавын аңлап-төшенеп җитте.

– Нәфисә... йә, кызма инде, акыллым. Тынычлан. Аңладым, барысын да аңладым. Нәрсә булды балаңа, шуны гына әйт тә...

– Белмибез бит... Авыр тын ала, сулышы югала... Тәне яна, ә аяк бармаклары суына, күз кабакларын да ача алмый, нарасыем...

– Балаңа ничә ай?

– Ике ай була инде.

– Имезәсеңме?

– Башта сөтем төшмәде... Аннары гына кайтты...

– Нәрсә ашадың?

– Ничек инде?

– Бүген нәрсә ашадың, дим.

– Анысы нәрсәгә инде?

– Җавап бир, нинди ризык каптың бүген?

– Көтү чыгаргач, авыл башындагы басу буеннан үткәндә борчак җыеп ашаган идем, сыер сауганнан соң сөт сөзеп эчтем, чишмә буенда юа өзеп каптым...

– Булды, башка сөйләмә! Бусы да җитеп торыр... Авыр ризыклар... Барысы да бала өчен авыр, аңлыйсыңмы? Бала имезгәндә теләсә нәрсә ашап йөриләр димени?! Әйдә киттек! – Морад,





Д. Нәүрүзова коллажы

җәһәт кенә торып, кул астындагы әйберләрен җыя да башлады.

– Кая? Кая чакырасыз мине, Морад агай?

Морад тиз генә җавап бирмәде. Иң элек урман буенда берничә урында укмашып торган милиция хезмәткәрләренә әмерләр биреп чыкты. Аннары гына Нәфисәгә таба борылды:

– Сезгә. Әйдә юл күрсәтерсең...

Алар кайтып кергәндә хәл үзгәрмәгән иде: бала шул килеш ята, калганнар өй эчендә ах-ух килеп йөриләр. Морад, тупсаны атлап керү белән, баш кагып кына исәнләште дә, кул юу өчен, мич артына юнәлде. Аннан чыгуга, бала бишеге янын килеп, бала өстенә бер карыш кала уң кул учларын җәеп җибәрде дә тын калды. Иләсләнеп, башын арткарак чөеп, күзләрен йомып берникадәр торганнан соң, җәһәт кенә хәрәкәтләр белән үрелеп, баланы кулына алды...

Сания сорамыйча булдыра алмады:

– Сез врачмы әллә?

Аңа Тәскирә белән Нәфисә кушылды:

– Сез баланы нишләтәсез?

– Нишлисез сез?

Морад Саниягә генә җавап бирде:

– Мин табиб түгел. Ләкин мин ата-бабалардан килгән халык дәвасын һәм шифасын беләм. Минем ата-бабаларым тирә-якта данлыклы имче-томчылар иде... Алар авыл читендә үз тирмәләре белән яшәгәннәр...

– Белмим инде, врач булмагач, ярый микән балага кагылырга? – Саниянең тавышында шикләнү-шөбһәләнү авазлары яңгырады.

– Ышанмыйсызмы? Ышанырга туры килер... Чөнки баланың вакыты бик аз калган... Ә инде ышануга килгәндә, шуны гына әйтә алам, – Морад берара Саниягә текәлеп карап торды, – менә сез сукыраеп терелгәнсез, шулаймы?

– Шулай....

– Димәк, ышандырдым? Миңа балага кагылырга ярыймы инде?

– Ярый... – Сания тәмам телсез, өнсез калды. Бүтәнчә, авыз ачып, бер сыңар сүз әйтмәде. Тулысынча Морад ихтыярына бирелде.

Морад исә, тынычланып, үз эшенә кереште. Ул иң элек баланы костырды, бүген сөт белән кергән бөтен ризыгын кире чыгарды. Шыңшып елый башлаган баланы тынычландыру чарасын да бик тиз тапты, – кулыннан алтын йөзеген салды да, җепкә кидереп, эчке якка, бишекнең урта бер җиренә элеп куйды. Бала, күз алдында пәйда булган ялтыравыкны күреп, шым булды, хәтта куллары белән үрелмәкче булып, чәбәләнә үк башлады, шатлыгын уртаклашырга теләп, үзе генә белгән телдә, медер-медер килеп, сөйләшергә кереште...

Ниһаять, Морад иң мөһим сүзне әйтте:

– Эш ризыкта гына түгел. Бума тигән бу балага. Ачыклыкта ялгызы калган идеме? – Морад бер Нәфисәгә, бер Тәскирә белән Саниягә каранды.

Нәфисә, гаеп эшләп тотылган баладай, бермәл борын тарткалап торды да, акланган кебек, басынкы тавыш белән:

– Кичә үзе генә ишегалдында яткан иде... Без инде... кайсыбыз кайда... Бәйләп куелган кебек, бала янында торган юк инде... – диде.

– Тс-с-с!.. – Морад ике учын да җәеп, йокыга китеп баручы бала өстенә куйды. Гыжлап сулыш алуын исәпкә алмаганда, ул хаста зәхмәтеннән котылган кебек иде. Милиция формасындагы кешенең им-томга керешүе көлке күренсә дә, тирә-яктагылар, бик җитди кыяфәт чыгарып, Морадка бөтен тәннәре һәм җаннары белән ярдәм итмәкче булып, бер рәткә тезелеп басканнар. Түр карават читендә утырган Ак бабай гына, учларын алдына җәеп тоткан да «Шәһәдәт кәлимәсе» пышылдарга керешкән иде: «Әшһәәду әлләә иләәһә иллаллаһу вә әшһәду әннә Мухәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһ...»

Бервакыт Морад учларын йоклап яткан бала өстеннән бөҗралатып йөртә башлады. Ара-тирә куллары кискен генә йә күтәрелеп, йә аска төшеп китә, йә булмаса, бармаклары калтыранып, дерелдәп тора башлый... Үзенең күзләре ярым йомык хәлдә, йөзендәге бар мускуллар да керчегенә җитеп тартылган... Берничә минуттан соң, учлары йомылып, бармаклары буынсыз булып калды, менә ул, кискен хәрәкәт ясап, кулларын бала өстеннән тартып алды. Һәм шундук тәрәзәгә үрелеп, өй каршында шаулап утырган биек агачларга карады. Ниһаять, бик авырсынып, әйтергә теләмәгән кебек кенә, бу сәер сеансның нәтиҗәсен игълан итте:

– Хаста агач башыннан кара болыт булып төшкән. Кешене баса торган, буа торган томан. Зәхмәтле шаукым, Нәфисә балакай, күбрәк синең белән бәйләнгән ул... Сәбәбе синдә... Әле дә шул яктан салкын кара нур булып суырылып килеп тора... Ул кара нур сиңа килеп сарыла, сизәсезме?..

Нәфисә дә, калганнар да берни сизмәүләрен белдертергә теләмәделәр, ахры, без берни дә аңламыйбыз дигән кебек, аптыраулы карашлары белән Морадка текәлеп, катып калдылар... Тик Ак бабай гына тынгысызланып, кыймылдап куйды. Өйдәгеләрдән ул гына белә Нәфисәдән албасты куу йоласы хакында. Бу албасты калдыгының, ерак китмичә, якындагы тупылларның берсенә кара болыт булып оялап калуы турында Хәлим шомланып сөйләгән иде. Ирәмәл дигән шаманның: «Көчен югалтса да, шаукымы кала аның, сак булыгыз!» – дигән кисәтүе хакында да белә Ак бабай. Әнә бит, әлегә кадәр ул тупылга кошлар кунмый, зәхмәт булмый, нәрсә булсын?! Алла сакласын!

Ә милиция башлыгы үзенең сихер кайтару йоласын дәвам итте. Бала тирәсендә ниндидер аңлашылмаган сәер хәрәкәтләр ясый-ясый, борынгы дәверләрдән үк телдән телгә күчеп килә торган, анда сөйләнелгән мифның тарихы, мәгънәсе инде онытыла башлаган әфсен такмагына кереште:

*Кара болыт киләдер,*
*Кара болыт астыннан*
*Кара сыер киләдер:*
*Мөгезе күккә терәлгән,*
*Җилене җиргә сөйрәлгән;*
*Бер имчәгеннән кан килә,*
*Бер имчәгеннән май килә,*
*Шуны аша да, шуны эч, –*
*Хәяткә тимә!*
*Кагылма!*
(Бераз дәшми торганнан соң)
*Име-томы шул булсын,*
*Каян килгән, шунда китсен!*

Әфсен өч тапкыр кабатланды. Һәр кабатлаганда Морад, өстәл читендәге кәсәдән бармак очларына сөт манып алып, як-якка сипте, аннары кисәк кенә Ак бабай ягына борылды:

– Кем... бабай, сезгә бу галәмәт хакында күбрәк билгеле. Дини кеше дә икән. Өйне чистартырга кирәк. Шактый бозылган аның һавасы, аурасы. Ә бала?.. Бала терелер. Бәхеткә, зәхмәти шаукымның сабый сулышын өзәргә көче җитмәгән. Хәзер ул бик озак килмәс инде. Ләкин бөтенләй килмәс дип әйтә алмыйм. Балага күз-колак булыгыз. Бигрәк тә сөйләшә башлаганчы. Сөйләшә башласа, ул үзе каршы тору юлларын табачак. Тел белән аң керә, зиһен ныгый... Ниндидер җир зәхмәте каныккан аңа. Аннары... баланың исеме ничек? Мин, «Хәят» дип, телемә килгән иң беренче исемне әйттем...

– Хәят, Хәят, чынлап та Хәят, – диештеләр хатын-кызлар.

Морад өйгә килеп кергәннән соң беренче тапкыр елмаеп җибәрде.

– Имче бабам ярдәм иткән, димәк... Рәхмәт аңа... – Менә ул кулларын күкрәк өстенә күтәреп, ике учын бер-берсенә каплап, башын өскә чөйде, күзләрен йомды, берничә мизгел шулай онытылып, иләсләнеп торды, аннары, кинәт кенә «уянып», өй эченә карап алды да нык адымнар белән тышка чыгып китте. Өйдәгеләр дәррәү аның артыннан кузгалды. Ак бабай гына үз урынында калды. Аның бик тә мөһим йола башкарасы бар иде. Монысы инде ихлас динебез кушкан изге гамәл булып, тәкбир кәлимәләре белән мәҗүси әфсенне каплап, бастырып куярга кирәк иде. Нинди генә изге нияттән башкарылса да, ул әфсеннең көче кеше рухын какшатып, өй эчен сихерләп калдырырга мөмкин бит. Ак бабай моны гына белә. Бу хакта Морад та белгән, юкса ул йортны дини дога белән чистарту хакында сүз катып торыр идемени?!

# «UENFEST». «Инвожо». «Сочи Парк»

**Кукмара районының «Инвожо» балалар фольклор коллективы сентябрь аенда Россиянең иң яхшы парк-аттракционы булган «Сочи Парк»та ял итеп кайтты. «UenFest» II Татарстан халыкларының традицион уеннары регионара фестивалендә җиңеп чыккан өчен шушы уникаль аттракционлы күңел ачу комплексында ял итү бәхете елмайды аларга.**













Фестивальнең йомгаклау этабы быелның 1 июнь көнне Казан Кремлендә үткән иде. Финалга чыккан командалар актив уеннарда ярыштылар һәм жюрига иҗади номерларын тәкъдим иттеләр.

«Безнең «Инвожо» фольклор коллективы исеменнән Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына һәм конкурсны оештыручы Мәдәни ресурслар үзәгенә рәхмәтләребезне җиткерәбез. Мондый бүләк өчен балаларыбыз бик шат», – диде коллектив җитәкчесе Геннадий Гайфетдин улы Әхмәтов.

Оештыручылар әйтүенчә, «UenFest» бәйгесе быел да игълан ителәчәк.







Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан



# КИЕЗ ИТЕК
## *читегем*

Наилә Яхина сүзләре һәм көе




Барыймны урманнарга?
Чыгыймны киң кырларга?
Йөрим уралып карларга,
Ис китми салкыннарга.

*Кушымта:*
Киез итек читегем,
Салкыннарда тик кидем.
Ап-ак кардан, энҗе кардан
Вак-вак атлап мин йөрдем.

Битем яна салкыннан,
Кояштанмы, ялкыннан?
Уйный-уйный минем белән,
Буран йөг(е)рә артымнан.

*Кушымта.*

Карап кала бар халык,
Гаҗәпләнеп, таң калып.
Ә мин йөрим, исем китми,
Читегемә сокланып.

*Кушымта.*

# ЧӘК-ЧӘК

«Татарханә» проектының «Татар табыны» рубрикасыннан. Чәк-чәк пешерү серләренә «Тәмле булсын» рестораннар челтәре житәкчесе, Татар ашлары һәм мәдәнияте Халыкара ассоциациясе президенты, Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, танылган аш-су остасы **Резидә Кыям кызы ХӨСӘЕНОВА** өйрәтә.

**Әйе, ул чәк-чәк! Татар теленә «чәк-чәк» сүзе фарсы теленнән кергән: «чәки-чәки», ягъни, «тамчы-тамчы» дигәнне аңлата. Җирле сөйләмнәрдә чәк-чәкнең түбәндәге вариантлары очрый. Мәсәлән, Казан арты һәм Оренбург татарлары чәк-чәкне «чәкчәги»; себер татарлары «чәкчәгәй» диләр. Нократ сөйләмендә «чепчәги», «чепчәк» вариантлары һәм Себер татарларында «цәкцәк» формалары да очрый.**

Чәк-чәк – камырны эрбет чикләвеге зурлыгында яки хөрмә кебек озынча итеп кисеп, кайнап торган сары майда пешереп, барысын бергә баллап катырып ясалган ашамлык. Ул һәр туй мәҗлесенең, никахның, милли ашларның, бәби (чәенең) туеның түрендә. Юка гына җиләк-җимеш кагына төргән чәк-чәк туйда хөрмәтле сыйлардан санала. Россиянең башка шәһәрләрендә, чит илләрдә яшәүче татарлар гына түгел, башка милләт кешеләре дә әлеге ризыкны ярата. Һәр төбәкнең үз чәк-чәге бар. Кайбер якларда аны токмач кебек кисеп пешерсәләр, чикләвек кебек түгәрәкләп ясаучылар да юк түгел.

Татарстан Республикасының Казан тирәсендәге районнарында яшәүче татарлар, гадәттә чәк-чәк пешерсә, республиканың көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан Әлмәт, Азнакай, Ютазы, Лениногорск, Бөгелмә, Баулы кебек ерак төбәкләрендә туйга килгән кунакларны бавырсак белән каршы алалар. Казан чәк-чәгеннән аермалы буларак, бавырсак эре итеп ясала.



## КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР

**Камыр өчен:**
800 грамм он,
6 данә йомырка,
3-4 аш кашыгы сөт,
ярты балкашыгы шикәр комы,
чәй содасы яки чүпрә, тәменчә тоз.

**Катнашма өчен:**
600 грамм бал,
200 грамм шикәр комы,
200 грамм стакан су,
кыздыру өчен 600 грамм көнбагыш мае.



### БАЛ ГЫНА, КҮБЕК КЕНӘ...

*Чәк-чәкнең барлыкка килүе турында мондый легенда да бар. Болгар ханы бердәнбер улын өйләндерергә карар кыла һәм туй өстәлендә җиңел әзерләнә, озак вакыт бозылмый торган, үз тәмен саклаучы сый куйлап табарга әмер бирә. Төп шарт – бу ризык һәр бәйрәмне бизәп торырга тиеш. Танылган аш-су осталары гына түгел, гади халык та үз сыен әзерләп карый. Хан күпсанлы ризыкларны татып карый, әмма алар арасыннан көтүче хатыны пешергән бер ризыкны – чәк-чәкне генә сайлап ала. Хан яшь парларга чәк-чәк бүләк итә. Ул балаларына бу чәк-чәкнең балы сыман бер-берсенә ябышып, тормышларының һәрчак тауга, югарыга үрелеп яшәүләрен, күпме борчак бар, шул чаклы онык бүләк итүләрен тели. Шул вакыттан бирле татар туйларында һәрвакыт чәк-чәк бүләк итәләр, имеш.*

*Чәк-чәк туйга кем ягында әзерләнүенә карап, «кияү чәк-чәге» (кияү ягында туй өчен әзерләнгән чәк-чәк), «кыз чәк-чәге» (туйга кыз ягында пешерелгән чәк-чәк), «кодагый чәк-чәге» (туйга кызның әнисе әзерләгән чәк-чәк) дип йөртелә.*

*Бүгенге көндә чәк-чәкне кисү, тарату кебек традицияләр күбесенчә туй йоласында сакланып калган. Мәсәлән, «чәк-чәк кисү» йоласы. Туйда чәк-чәкне өлешләп кисәсе кеше алдан билгеләнә.*

*Оренбург татарларында исә «чәк-чәки ачу» йоласы сакланган. Ул чәк-чәкне бүләк салып, котлап ачудан гыйбарәт. Нократ ягы татарларында «Чепчәги йолдыру» йоласы, ягъни туйда чәк-чәкне котлап акча салу традициясе һаман да яши. Татарстан Республикасының Минзәлә районы авылларында «чәк-чәк чәчү» йоласы сакланган. Килен табынга утыргач, туйга килгән бала-чагаларга чәк-чәк «чәчәләр» (тараталар).*



**1**

Чәк-чәк камырын ясау өчен алты йомырканың өчесен шул килеш, ә өчесенең сарысын гына сытабыз. Ярты бал кашыгы чәй содасы, бер чеметем тоз, өч-дүрт аш кашыгы сөт салып бөтенесен бергә туглыйбыз. Онны аз-азлап кына салып, йомшак кына камыр басабыз.



**2**

Тактага бушатып, аңа әз-әзләп он куша-куша камырны үзләндерәбез. Камыр әзер булгач, дүрткә бүлеп, һәр кисәкне җәябез. Махсус кискеч белән җәемнәрне кисәбез.



**3**

Көнбагыш маен кыздырырга куябыз. Май кызгач, махсус кискеч белән киселгән камырларны кызган майга салып пешерәбез. Пешеп чыккан һәр өлешне, маен саркытырга, тишекле чүмечкә (дуршлагка) сала барабыз, аннары табакка бушатабыз.





**4**

Бер стакан суга 200 грамм шикәр комы салып, кайнатырга куябыз. 10 минуттан соң аңа бал өстибез. Катнашманың әзерлеген белү өчен, аны суга салып карыйбыз. Әгәр дә катнашма суда шарчыклар хасил итсә, ул әзер дигәнне аңлата.



**5**

Әзер катнашманы табактагы чәк-чәккә агызып, болгатабыз. Чәк-чәк ябышмасын өчен кулны салкын суга тыгып алабыз. Махсус әзерләнгән савытка, тәлинкәгә чәк-чәкне матур итеп өябез. Өстен махсус конфитерлар, чәлпәк (роза чәчәге) белән бизибез дә катырырга куябыз.



**6**

Чәк-чәкне табынга бөтен килеш бирәләр. Бу вакытта, аеруча туй-никах мәҗлесләрендә чәк-чәк сату-алу йоласы башкарыла. Чәк-чәкне ромб рәвешендә дә кисеп бирергә мөмкин.

**Ашларыгыз тәмле булсын!**

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Шахворд

Хөрмәтле укучылар! Таблицадагы хәрефләр тезмәсеннән шахмат фигурасы «ферзь»нең дөрес йөреш тәртибен кулланып, шигъри дүртьюллык укыгыз.

| ♕ | 2 | 3 | 9 | 10 | 20 | 21 | 35 | 36 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 4 | 8 | 11 | 19 | 22 | 34 | 37 | 52 |
| 5 | 7 | 12 | 18 | 23 | 33 | 38 | 51 | 53 |
| 6 | 13 | 17 | 24 | 32 | 39 | 50 | 54 | 65 |
| 14 | 16 | 25 | 31 | 40 | 49 | 55 | 64 | 66 |
| 15 | 26 | 30 | 41 | 48 | 56 | 63 | 67 | 74 |
| 27 | 29 | 42 | 47 | 57 | 62 | 68 | 73 | 75 |
| 28 | 43 | 46 | 58 | 61 | 69 | 72 | 76 | 79 |
| 44 | 45 | 59 | 60 | 70 | 71 | 77 | 78 | 80 |
| | | | | 85 | 84 | 83 | 82 | 81 |

**Шахворд җавабы – саннарда**

Бер сан бер хәрефкә туры килә. Дүртьюллык 85 хәрефтән тора.

| ♕ | ш | ь | г | ә | р | л | г | о |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Я | к | н | - | ә | ә | н | м | ы |
| и | е | п | д | р, | ы | е | с | н, |
| л | а | н | Т | с | р | л | г | ы |
| р | е | а | а | г | у | е | с | н, |
| м | п | м | ә, | б | л | л | С | и |
| к | н | Й | к | п | у | а | б | р |
| у | о | а | а | б | ф | к | с | к |
| м | ш | к | ъ | л | ы | е | н | ү |
| | | | | ә. | г | л | е | ң |

**Шахвордның җавабы**

Яшь киленгә – пар мендәрләр,
Тап кунмасын гомергә.
Йомшак булсын, гел пакь булсын,
Сафлык бирсен күңелгә.

**Педагогия фәннәре кандидаты, Халыкара педагогик белем фәннәре академиясе академигы Нәҗип ШАКИРҖАНОВ төзеде**

# Истәлекле даталар
## 2023

### ГЫЙНВАР

**1 гыйнвар**
Язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Мансур Хаҗи улы Вәлиевкә 75 яшь (1948)

**3 гыйнвар**
Шагыйрь, драматург ТАССРның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстанның М. Җәлил исемендәге Республика, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Илдар Гафур улы Юзеевның туууына 90 ел (1933-2004)

**3 гыйнвар**
Актёр, Татарстанның М. Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты Нариман Габдрахман улы Гарифуллинга 70 яшь (1953)

**3 гыйнвар**
Шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мөхәммәт Мирзага (Илфак Мирзамөхәммәт улы Ибраһимовка) 70 яшь (1953)

**15 гыйнвар**
Җырчы, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әлфия Авзал кызы Авзалованың туууына 90 ел (1933-2017)

**15 гыйнвар**
Җырчы, ТАССРның халык артисты Нәфисә Василованың (Анастасия Петровна Васильева) туууына 80 ел (1943-2006)

**16 гыйнвар**
Балалар язучысы, шагыйрь, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге премиясе лауреаты Хәкимҗан Шәяхмәт улы Халиковның туууына 90 ел (1933-2002)

**20 гыйнвар**
Баянчы, музыкаль фольклор җыючы, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Рокыя Габдрахман кызы Ибраһимованың туууына 110 ел (1913-1998)

**27 гыйнвар**
Театр белгече, педагог, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Рауза Фатих кызы Усмановaның туууына 100 ел (1923-2014)

**29 гыйнвар**
Актёр, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәрим Ибраһим улы Гыйльмановның туууына 110 ел (1913-1964)

### ФЕВРАЛЬ

**3 февраль**
Җырчы, Татарстан Республикасының халык артисты Галина Александровна Казанцевага 70 яшь (1953)

**12 февраль**
Язучы, журналист, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Шаһинур Әхмәтсафа улы Мостафинның туууына 75 ел (1948-2020)

**13 февраль**
Бөек рус җырчысы, Россиянең халык артисты Фёдор Иванович Шаляпинның туууына 150 ел (1873-1938)

**15 февраль**
Фольклорчы галим, филология фәннәре докторы, ТАССРның, РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хуҗи (Хуҗиәхмәт) Шаһиәхмәт улы Мәхмүтовның туууына 90 ел (1933-2021)

**22 февраль**
Рәссам Равил Халит улы Шәрәфетдиновның туууына 75 ел (1948-1995)

### МАРТ

**1 март**
Урта махсус уку йорты – Казан хореография училищесы ачылуга 30 ел (1993)

**4 март**
Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Айрат Сәлимулла улы Шәмсетдиновка 60 яшь (1963)

**10 март**
Актёр, режиссёр, ТАССРның халык артисты Хәким Йосыф улы Сәлимҗановның туууына 120 ел (1903-1981)

**12 март**
Рәссам Илгиз Мәснәви улы Хановка 75 яшь (1948)

**23 март**
Рәссам Леонид Витальевич Захаровның туууына 75 ел (1948-2005)


**26 март**
Рәссам, график, педагог Валентина Витальевна Поповaның туууына 90 ел (1933-2011)

**29 март**
Скульптор, ТАССРның халык рәссамы Садри Сәлах улы Ахунның (Ахунов) туууына 120 ел (1903-1987)

https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды










**Кадерле укучыларыбыз!**
2023 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России»
сайты аша (https://podpiska.pochta.ru
Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.
**Индексыбыз – ПА 183**
**Өч айга язылу бәясе – 283 сум 39 тиен**
**Ярты елга язылу бәясе – 566 сум 78 тиен**

БЕРГӘ БУЛЫЙК, ДУСЛАР!